80 ПОБЕДА!

# ТАТАРСТАН – ФРОНТКА



# ТАТАРСТАН – ФРОНТУ

Бу китап – Ватаныбыз тарихындагы иң әһәмиятле сәхифәләргә мавыктыргыч сәяхәт ул. Әлеге сәяхәткә Роман, Зөләйха һәм ярдәмче самолёт белән бергә чыгарбыз. Китапны барлык гаилә әгъзалары белән укыгыз.

Эта книга – увлекательное путешествие по самым значимым страницам истории нашей Родины. В это путешествие отправимся вместе с Романом, Зулейхой и самолётиком-помощником. Читайте её вместе со всеми членами семьи.

Зөләйха
Зулейха



Роман һәм Зөләйха – «Мирас угы» анимацион фильмы һәм китабы геройлары.

Мультфильмны кара
www.стреланаследия.рф

Посмотри мультфильм
www.стреланаследия.рф


Роман и Зулейха – герои анимационного фильма и книги «Стрела наследия».

Китапта сез **QR-кодлар** очратырсыз. Аларны сканерларга гына кирәк: кодларны смартфон камерасына күрсәтегез һәм сылтамага басыгыз. Шулай итеп сез, китапка өстәмә буларак, фильм, ролик яки текстлы сәхифәне ачарсыз.



В книге вы найдёте **QR-коды**. Их нужно просто **сканировать**: наведите на них камеру смартфона и нажмите на ссылку. Так вы попадёте на страницу с фильмом, роликом или текстом в дополнение к книге.





ПОмощник

Роман



Һәр бүлек азагында Татарстан рәссамнарының Бөек Ватан сугышы темасына багышланган картиналарының репродукцияләре һәм Җиңү бәйрәме алдыннан балалар арасында уздырылган рәсем конкурсында җиңүчеләрнең кайбер эшләре тәкъдим ителде. Барлык рәсемнәрне www.татарстанфронту.рф сайтының «Конкурс» бүлегендә таба аласыз.



ТАТАРСТАН – ФРОНТКА

Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында
Художники Татарстана о Великой Победе

Әхмәт Китаев 1965 Ахмед Китаев

МУСА ҖӘЛИЛ МОАБИТ ТӨРМӘСЕНДӘ

Рәссам Әхмәт Китаев зур картиналар ясарга ярата. Аларда еш кына Бөек Ватан сугышы күренешләре чагылыш таба.

Бу картинада татар шагыйре Муса Җәлил сурәтләнгән. Ул сугыш вакытында әсирлеккә алына һәм төрмәгә ябыла. Картинада без бик караңгы һәм шыксыз бүлмә күрәбез. Муса Җәлил ертык зиндан киеменнән, иңбашына пычрак плащ капланган, әмма аның рухы сындырылмаган. Ул бирешми, баш ими! Шагыйрь еракка, яктылыкка карый. Картинаның иң якты элементы – Муса Җәлилнең төрмәдә язган шигырьләр китабы. Бу китап – аның безгә калдырган ядкәре.

МУСА ДЖАЛИЛЬ В МОАБИТСКОЙ ТЮРЬМЕ

Художник Ахмед Китаев любил писать картины крупного размера. На них он часто показывал сцены Великой Отечественной войны.

На данной картине изображён татарский поэт Муса Джалиль. Он был взят в плен во время войны и брошен в тюрьму. На картине мы видим очень мрачную, угрюмую и тёмную камеру. Сам Муса Джалиль одет в оборванную тюремную одежду, на плече у него грязный плащ, но дух его не сломлен. Он не сдаётся! Поэт смотрит вдаль, на свет. Самый яркий элемент картины – книга со стихами, которые Муса Джалиль написал в тюрьме. Это сокровище, которое он оставил всем нам.

«Моабит дәфтәре» фильмын кара

Посмотри фильм «Моабитская тетрадь»

28

ТАТАРСТАН – ФРОНТУ

Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре
Рисунки детей – к юбилею Великой Победы

Станислав Волков рәсеме.
Кайбыч муниципаль районы «Берёзка» Зур Подберезье балалар бакчасы

Рисунок Станислава Волкова.
Большеподберезинский детский сад «Берёзка» Кайбицкого муниципального района

Арсений Пономарёв рәсеме.
Алабуга муниципаль районы 29 нчы «Алтын балык» катнаш төргәге балалар бакчасы

Рисунок Арсения Пономарёва.
Детский сад комбинированного вида №29 «Золотая рыбка» Елабужского муниципального района

29

В конце каждой главы представлены репродукции картин художников Татарстана на тему Великой Отечественной войны и некоторые работы победителей конкурса детских рисунков, прошедшего в преддверии празднования Дня Победы в нашей республике. Все рисунки можно найти на сайте www.татарстанфронту.рф в разделе «Конкурс».

УДК 821.512.145-93
ББК 83.84(2=632.3)6-442,
Т23

Әлеге китап Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы
уңаеннан чыгарыла һәм гаилә белән бергәләп уку,
дәрестән тыш чараларда куллану өчен тәгаенләнә.

ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО

Книга приурочена к 80-летию Победы
в Великой Отечественной войне и предназначена
для семейного чтения и внеурочной деятельности.

ISBN 978-5-6050161-8-2
© Татарское детское издательство, 2025

80
ПОБЕДА!

# ТАТАРСТАН – ФРОНТКА



# ТАТАРСТАН – ФРОНТУ

# Кадерле дустым!

Бүген синең мәктәптә беренче көнең. Янәшәңдә – якын кешеләрең, ягымлы укытучылар, яңа дуслар. Бу шатлыклы, тыныч көнне сиңа Ватаныбыз өчен хезмәт куйган һәм көрәшкән әби-бабаларыбыз бүләк итте.

2025 ел – Ватанны саклаучылар елы һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы.

Татарстанлылар уртак эшкә зур өлеш керттеләр – фронтта каһарманнарча сугыштылар, тәүлекләр буе тылда эшләп, илгә ярдәм иттеләр. Әлеге батырлыклар турында фотосурәтләр, китаплар, фильмнар сөйли, алар турындагы истәлекләр һәйкәлләрдә мәңгеләштерелгән.

Тарихны онытма – аннан башка киләчәк юк.

Халкыбызның батырлыгы белән горурлан!

Татарстан Республикасы Рәисе Р. Н. Миңнеханов

# Дорогой друг!

Сегодня твой первый день в школе. Рядом с тобой – близкие люди, приветливые учителя, новые друзья. Этот радостный, мирный день подарили тебе твои предки, которые трудились и сражались за нашу Родину.

2025 год – Год защитника Отечества и 80-летия Победы в Великой Отечественной войне.

Татарстанцы внесли огромный вклад в общее дело – храбро и мужественно воевали на фронте, помогали стране, круглосуточно работая в тылу. Об их подвигах повествуют фотографии, книги, фильмы, воспоминания о них увековечены на памятниках.

Не забывай историю – без неё нет будущего.

Гордись подвигом нашего народа!

Раис Республики Татарстан Р. Н. Минниханов



# Сүз башы

Кадерле балалар!

Сез кулыгызга алган китап 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы турында сөйли.

Безнең халыкның немец-фашист илбасарларына каршы сугышы 1941 елның 22 июнендә таң атканда башланып, дүрт елга якын – 1418 көнгә сузыла.

Бөтен ил көрәшкә күтәрелә. Фронтта* һәм тылда халык – ирләр дә, хатын-кызлар да, егетләр дә, кызлар да, өлкәннәр дә, хәтта балалар да – җиңү өчен кулдан килгәннең барысын да эшлиләр.

Дошман һөҗүмен беренчеләрдән булып Брест крепосте каршы ала. Аның героик оборонасында дүрт меңгә якын кеше катнаша.


Фашист гаскәрләренең Ленинградны (хәзер Санкт-Петербург) камап алуы фаҗигале вакыйга була. Блокада* 872 көн дәвам итә. Ул 1944 елның 18 гыйнварында өзелә.

1942 елның 17 июлендә Сталинград сугышы башлана. Ул 200 көн һәм төн дәвам итә. Армиябезнең бу җиңүе сугыш барышында борылышның башы була.

Бөек Ватан сугышында 1943 елның җәендә булган Курск бәрелеше аерым урын алып тора. Ул фашистларның зур танк берләшмәләрен тар-мар итү белән тәмамлана.

Совет армиясе дошман басып алган Европа илләрен азат итә һәм Берлинга кадәр барып җитә. 1945 елның 30 апрелендә безнең сугышчылар Германия башкаласының төп бинасы булган рейхстаг* өстенә Җиңү байрагын күтәрәләр.

1945 елның 8 маенда фашистлар Германиясе үзенең тулысынча җиңелүен таный. Икенче көн, 9 Май, шул вакыттан бирле безнең өчен бөек бәйрәм – Җиңү көне!




Фронт – сугыш хәрәкәтләре бара торган урын, территория.

Блокада – дошман гаскәрләренең шәһәрне камап алып, анда азык-төлек, дарулар һәм башка кирәк-яракларны керттермәве.

Рейхстаг – Германия башкаласы Берлинда мөһим карарлар кабул итү өчен ил җитәкчеләре җыела торган бина.

# Предисловие

Дорогие ребята!

Книга, которую вы держите в руках, рассказывает о Великой Отечественной войне 1941–1945 годов.

Война нашего народа с немецко-фашистскими захватчиками началась на рассвете 22 июня 1941 года и продлилась почти четыре года – 1418 дней.

На борьбу поднялась вся страна. И на фронте*, и в тылу мужчины и женщины, юноши и девушки, пожилые люди и даже дети – все делали всё для победы.

Одной из первых приняла на себя удар врага Брестская крепость. В её героической обороне участвовали около четырёх тысяч человек.

Трагическим событием стала блокада* Ленинграда (ныне Санкт-Петербург) – окружение города фашистскими войсками. Она продолжалась 872 дня. Прорвать блокаду удалось 18 января 1944 года.

17 июля 1942 года началась Сталинградская битва. Она длилась 200 дней и ночей. Эта победа нашей армии стала началом перелома в ходе войны.

Особое место в Великой Отечественной войне заняла Курская битва летом 1943 года. В этом сражении было разгромлено одно из самых крупных фашистских танковых соединений.

Советская армия освободила оккупированные врагом европейские страны и дошла до Берлина. 30 апреля 1945 года наши бойцы водрузили Знамя Победы над рейхстагом* – главным зданием немецкой столицы.

8 мая 1945 года фашистская Германия признала своё полное поражение. Следующий день, 9 мая, с той поры стал для нас великим праздником – Днём Победы.

**Фронт** – место, территория, где проходят военные действия.

**Блокада** – окружение города войсками противника и прекращение поставок в него еды, лекарств и других важных вещей.

**Рейхстаг** – здание в столице Германии – Берлине, где собирались для принятия решений руководители государства.





# Беренче бүлек. Серле сурәт

Рома һәрвакытта кызыксынучан бала булды. Шуңа да җае чыкканда, мөмкин булган урыннарда казу эшләре алып бара, ә кайчагында ул үзенчәлекле табышларга да юлыга иде.

Бу юлы да чорманың караңгы почмагында торган фанера такта артында күпне күргән бер сандыкка тап булды. Сандык төбендә фотография ята иде. Ул гаилә альбомыннан төшеп калган булса кирәк. Фото шактый иске, саргаеп беткән иде инде. Шулай да каен янында басып торган бер малай яхшы гына шәйләнә. Кызганыч, артындагы язулары да танымаслык дәрәҗәдә уңган булып чыкты.



# Глава первая. Загадочный снимок

Рома всегда был любознательным. Поэтому время от времени проводил раскопки везде, где мог. Иногда и в самом деле находил что-нибудь особенное.

На этот раз в тёмном углу чердака за фанерным щитом он обнаружил явно повидавший виды сундучок. На дне его лежала фотография, похоже, выпавшая из семейного альбома. Снимок был уже пожелтевший, но на нём можно было разглядеть мальчишку возле берёзы. Оборотная сторона фотографии ясности не добавила: если надписи там и были, то давно стёрлись...

– Бөтен нәрсәне тәртип белән эшләргә кирәк, – диде Зөләйха икенче көнне, табылдыкны җентекләп карагач. – Башта туганнарга күрсәтергәдер...

– Күрсәттем инде... – диде Рома күңелсез генә.

– Димәк, эзләү даирәсен киңәйтергә кирәк. Ерак туганнар бар, гаилә дуслары... Фотоны Интернетка да куярга була.

Әмма эш алар уйлаганнан катлаулырак булып чыкты. Интернет аша фотодагы малайны танучы табылмады. Төрле сайтларда мөстәкыйль рәвештә алып барган эзләнүләр дә нәтиҗә бирмәде. Күршедә яшәүче Роза әбинең дә хәтер янчыгында кирәкле мәгълүмат юк иде. Әтиләренең дусты Фоат Саматович та, белмим, дип баш селкеде. Ярты шәһәр белән таныш Галя апа да чарасызлыктан кулларын гына җәйде. Таныш фотограф Вова дәдәй, уйланып торгач, сурәтнең бик иске – ихтимал, сугыш вакытында ук, хәтта әле сугышка кадәр үк төшерелгән булуын искәртте дә, игътибар белән тагын карармын әле, дип өстәп куйды.

– Берәр яңалык булса, хәбәр итәрсезме?

– Сөйләштек, – диде Вова дәдәй.

– Бәлки музейга барып карагадыр? – дип фикер йөртте Зөләйха. – Тапмасалар да, берәр киңәш бирерләр әле.

Рома Интернеттан аерылмый гына җилкәсен сикертте дә авыр сулап куйды. Һәм, уйлап-нитеп тормыйча, яңа хатны ачты.



– Так, действуем по порядку, – заявила на следующий день Зулейха, рассмотрев находку. – Сначала покажем родственникам...

– Уже показывал... – грустно сказал Рома.

– Значит, расширяем зону поиска. Дальняя родня, друзья семьи... Заодно в Интернете разместим.


Но дело оказалось труднее, чем они думали. Из Интернета отклика не было, самостоятельные поиски по разным сайтам результата не дали. Соседка, баба Роза, ничего полезного не припомнила. Фоат Саматович, папин друг, отрицательно покачал головой. Тётя Галя, у которой знакомых полгорода, только руками развела. Лишь знакомый фотограф дядя Вова заметил задумчиво, что снимок, наверно, военного времени или даже довоенных лет. И добавил, что посмотрит внимательней.

– Если что-то новое будет, скажете? – спросил Рома.

– Ладушки, – сказал дядя Вова. Это было его фирменное словечко.

– Может, в музей обратиться? – размышляла вслух Зулейха. – Не найдут, так хоть подскажут что-нибудь.

Рома, продолжая искать в сети, пожал плечами и вздохнул. И автоматически открыл новое письмо.



– Тукта, япмый тор. Хатка салынган файлны ачып карыйк әле, – диде аңа хат килгәнне күреп алган Зөләйха.

Хат эчендәге файл тавыш белән яздырылган иде. Тавышы тигез, әмма сәеррәк. Хәер, хат язучының исеме дә сәер иде – «Сезнең Ярдәмче».

«Сәлам, дуслар, – диде әллә дәрестә логопед сөйләшкәнне, әллә фантастик фильмнардагы роботны хәтерләткән тавыш. – Мин – Ярдәмче. Мин сезнең соравыгызга җавапны белмим, ләкин сезне бер сәяхәткә чакырам, ахырда табышмакның серен үзегез ачарсыз. Чөнки бу фото ясалган чорны яхшырак аңлаячаксыз. Риза булсагыз, бу хатка җавап бирегез дә сәфәргә әзерләнегез».



– Подожди, не закрывай! – сказала из-за его плеча Зулейха. – Давай вложение посмотрим...

Вложение оказалось звуковым сообщением. Голос был ровный, но странноватый. Как, собственно, и имя отправителя – «Ваш ПОмощник» (именно так: в слове «ПОмощник» две первые буквы заглавные).

«Привет, ребята, – произносил голос то ли как логопед на занятии с учениками, то ли как робот в фантастическом фильме. – Я – ПОмощник. Ответа на ваш вопрос я не знаю, зато помогу вам совершить путешествие, и тогда вы разгадаете загадку сами. Потому что будете лучше понимать время, когда этот снимок был сделан. Если вы согласны, ответьте на это письмо и будьте готовы».



...Озак көтәргә туры килмәде.

Төштән соң якындагы парктагы эскәмиядә утырганда, алар Ярдәмчене шунда ук күреп алды. Дөресрәге, башта күрмәделәр, ишеттеләр.

– Исәнлек телим! – диде таныш тавыш. – Сәлам, дуслар!

Рома белән Зөләйха як-якларына карандылар. Әйләнә-тирәдә берәү дә юк иде. Каршыдагы эскәмиядә утырган өлкән яшьтәге бер кеше генә күзлеген төзәтеп куйды да китабының чираттагы битен ачты.

...Ждать пришлось недолго.

ПОмощника они увидели сразу, когда после обеда сидели на скамейке в парке по соседству. Вернее, не увидели, а услышали.

– Здравия желаю! – голос был уже знакомый. – Привет, ребята!

Рома и Зулейха оглянулись. Вокруг никого не было. Только старичок на скамейке напротив поправил очки и перевернул очередную страницу книги.

Это интересно / Бу кызык

Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан АССРның 700 000 гә якын улы һәм кызы, кулларына корал тотып, Ватаныбызны саклый.

Около 700 000 сыновей и дочерей Татарской АССР с оружием в руках защищали нашу Родину в годы Великой Отечественной войны.

«Татарстан – Бөек Җиңүгә» плакатларын кара

Посмотри плакаты «Татарстан – Великой Победе»

– Хәзер, хәзер... – диде шул ук тавыш янәшәдә генә. – Булды, әзер!

Һәм алар, үз күзләренә ышанмыйча, ниһаять тавыш иясен күреп алдылар. Ул кеше түгел иде. Ул Рома белән Зөләйхага китап битләрендә яки телевизор экраннарында гына очраганы булган иске самолёт иде. Тик кечкенә һәм, ике ягында утлары янгандай, бераз гына яктылык сирпи. Үзе тагын һавада эленеп тора, әйтерсең лә самолёт түгел, ә вертолёт.

– Бу мин, – диде ул, – сезнең Ярдәмче. Мине По-2 дип атый аласыз. Китаплардагы кебек.

– Сез бит самолёт. Сез ничек сөйләшәсез?!

– Мин сөйләшмим, уйлыйм гына. Ләкин сез ишетерлек итеп уйлыйм. Минем галим дусларым бик күп. Шуңа да мин күп нәрсәгә өйрәндем... Озакламый үзегез дә моңа инанырсыз. Билгеле инде, әгәр сез чыннан да зур сәяхәткә әзер булсагыз...

– Сейчас... – сказал рядом тот же, из сообщения, голос. – Всё, готово!

И они, не веря своим глазам, увидели наконец, от кого исходил голос. Это был не человек. Это был самый настоящий старый самолёт, из тех, что ребятам доводилось встречать лишь на книжных страницах или в телесюжетах. Только маленький и слегка светящийся. А ещё он висел в воздухе, словно это был не самолёт, а вертолёт.

– Это я, – сказал он, – ваш ПОмощник. Можно – По-2. Как в книгах.

– Вы же самолёт... Как вы разговариваете?!

– Я не разговариваю, я просто думаю. Но так, что вы меня слышите. Друзей-учёных у меня много, так что и я кое-чему научился... Скоро сами убедитесь. Если вы, конечно, готовы к путешествию...






Рома белән Зөләйха, ниһаять, гаҗәпләнүдән туктап:

– Әзер! Әзер! – диештеләр.

– Ә еракка булса?

– Еракка да әзер!

– Ә еллар-чорлар гизәргә?

Зөләйха белән Рома аптырап авызларын ачтылар. Әмма шунда ук яптылар. Бер-берсенә карашканнан соң, ризалык белдереп, баш кактылар.

– Алайса – юлга!

Каршы эскәмиядә утырган бабай, гаҗәпләнеп, башын күтәрде дә:

– Сез кем белән сөйләшәсез? – дип сорады.




Ребята наконец перестали хлопать ресницами.

– Готовы! Готовы!

– А к далёкому?

– Готовы!

– А во времени?

Зулейха и Рома раскрыли рты. Но тут же закрыли. И, взглянув друг на друга, молча закивали.

– Тогда в путь!

Сосед на скамейке напротив удивлённо поднял голову:

– С кем это вы разговариваете?





– Ул сезне күрмимени? – дип сорады Рома Ярдәмчедән.

– Нәкъ шулай, күрми, – диде тегесе һәм утлары белән җемелдәтеп алды. – Хәер, шушы мизгелдән сезне дә күрми: без хәзер вакыт капсуласында. Башыгыз әйләнеп китсә, курыкмагыз... Бетә ул.

Кинәт балалар яңа танышлары – самолёт эчендә утыруларын күреп шаккаттылар.

– Ой! Без нәрсә, кечерәйдекме әллә?!

– Нәкъ шулай, – дип аңлатты берни булмагандай Ярдәмче. – Мин бит сезгә күп нәрсәгә өйрәндем, дидем...

Каршында утырган бабай берни аңламыйча аптырап калды:

– Нәрсә булды?! Әле генә монда иделәр! Кай арада юкка чыктылар?!

Ул аларның кая юкка чыкканнарын белсә икән...

– Он, что, вас не видит? – спросил ПОмощника Рома.

– Точно так, не видит, – сказал тот и мигнул огоньками. – А с этой секунды – и вас, между прочим. Мы в капсуле времени. Не бойтесь: это безопасно. Разве что голова сначала чуть кружиться будет. Но это пройдёт.

Ребята вдруг с изумлением обнаружили, что сидят прямо на корпусе своего нового знакомца.

– Ой! Мы что, уменьшились?!

– Именно, – как ни в чём не бывало объяснил ПОмощник. – Я же сказал, что многому научился...

Старичок на скамейке недоумённо заморгал:

– Что такое?! Куда они исчезли?!

Если бы он только знал куда...

# Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында

# Художники Татарстана о Великой Победе



1974

Константин Васильев

## СЛАВЯН ХАТЫННЫҢ ХУШЛАШУЫ

Рәссам Константин Васильев Яшел Үзән районындагы бистәдә яшәгән. Хәзер бу бистә рәссам хөрмәтенә Васильево дип атала. Васильевның күп кенә картиналары сугыш темасына багышланган.

«Славян хатынның хушлашуы» картинасында без, чиксез озын колонна булып, Ватаныбызны яклау өчен сугышка китеп баручы солдатлар сафын күрәбез. Сугышчыларга хатын-кыз һәм бала карап тора. Алар тыныч, Җиңүгә ышаналар. Хатын-кызның артында – кызыл ут ялкыны, соры болытлар. Алар куркыныч якынлашуы турында кисәтә. Картина уртасындагы якты нур көч бирә һәм Җиңүгә ышаныч уята торган өмет булып тора.

Константин Васильев

## ПРОЩАНИЕ СЛАВЯНКИ

Художник Константин Васильев жил в посёлке в Зеленодольском районе. Сейчас этот посёлок носит его имя – Васильево. Васильев часто писал картины про войну.

На картине «Прощание славянки» мы видим строй солдат, которые нескончаемой колонной отправляются в бой на защиту нашей Родины. На них смотрят женщина и ребёнок. Они стоят спокойно. Они верят в Победу. За спиной женщины – красное пламя, серые тучи. Они предупреждают о надвигающейся угрозе. Светлый луч в середине картины – надежда, которая даёт силы и веру в Победу.

# Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре

# Рисунки детей к юбилею Великой Победы



Никита Свиягин рәсеме.
Минзәлә муниципаль районы 8 нче номерлы гомуми үсеш тибындагы «Кояшкай» балалар бакчасы


Рисунок Никиты Свиягина.
Детский сад общеразвивающего вида №8 «Солнышко» Мензелинского муниципального района




Виталина Емельянова рәсеме.
Казан шәһәре Мәскәү районының 345 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы

Рисунок Виталины Емельяновой.
Детский сад №345 комбинированного вида Московского района города Казани

ТАТАРСТАН – ФРОНТКА



# Икенче бүлек. Нәкъ менә шул ел

...Аяз күк йөзен кояш яктырта, тик урамдагы кешеләрнең анда бөтенләй гамьнәре юк иде. Алар барысы да баганага эленгән репродукторны* тын калып тыңлыйлар иде.

– Совет информбюросыннан*...

Диктор немец гаскәрләренең Советлар Союзына һөҗүм итүе турындагы хәбәрен әйтеп бетерүгә, халык басынкы тавыш белән генә сөйләшә башлады. Аннан соң хатын-кызлар кычкырып җибәрде, балалар елаша башлады, халык гөж килде: «Сугыш... Сугыш... Сугыш бу...»

– Сез кайсы елга килеп эләккәнебезне аңладыгызмы? Кайсы көнгә? – дип сорады Ярдәмче.

– Әйе, – дип җавап бирде Рома, ни өчендер пышылдап. – Мин аңладым. 1941 елның 22 июне. Бабам сугыштан соң гына туган булса да, ул хакта күп сөйли иде.

Репродуктор – тавышны көчәйтеп тапшыру җайланмасы, тавышкөчәйткеч.

Совет информбюросы – Бөек Ватан сугышы елларында халыкка фронт яңалыкларын хәбәр итеп торган оешма.

# Глава вторая. Тот самый год

…В ясном небе светило солнце, но людям на улице явно было не до погожего дня. Они стояли, повернув головы к висевшему на столбе репродуктору*, слушали и молчали.

– От Советского информбюро*…

Когда диктор закончил сообщение о нападении немецких войск на Советский Союз, в толпе сдавленными голосами начали переговариваться. Затем закричали женщины, заплакали дети, и вся толпа глухо зашумела: «Война… Война… Это война…»

– Вы поняли, в какой год мы попали? В какой день? – спросил ПОмощник.

– Да, – ответил почему-то шёпотом Рома. – Я понял. Это 22 июня 1941 года. Мне дедушка рассказывал, хотя сам он уже после войны родился…

Репродуктор – устройство для громкой передачи звука, громкоговоритель.

Советское информбюро – организация, которая в годы Великой Отечественной войны сообщала народу о положении на фронтах.

Это интересно / Бу кызык



Казан аэроклубында тәрбияләнгән Дмитрий Кокорев 22 июньдә иртә таңнан, беренчеләрдән булып, һава тараны* ясый. МиГ-3 пулемётларында патроннар бетә, истребительләр звеносы командиры немец бомбардировщигының койрыгын винты белән кыеп төшерә һәм дошман машинасын юкка чыгара.

Выпускник Казанского аэроклуба Дмитрий Кокорев ранним утром 22 июня одним из первых совершил воздушный таран*. Патроны в пулемётах его МиГ-3 кончились, и командир звена истребителей винтом разрубил хвостовое оперение немецкого бомбардировщика, уничтожив вражескую машину.

Таран – зыян салыр өчен, башка корабка, очкычка, машинага махсус бәрелү.

Таран – намеренное столкновение с другим кораблём, самолётом, машиной, чтобы нанести вред.

Д. Кокорев турында видео кара

Посмотри видео о Д. Кокореве

– Дөрес. Нәкъ шул ел, нәкъ шул көн... Без монда озак булмабыз, әмма сез аның ничек башланганын үз күзләрегез белән күрергә тиеш. Чөнки сезнең кулдагы фотография шул вакытныкы.

Күз алдындагы манзара эреп югала башлады. Сәяхәтчеләребез моның нилектән икәнен инде аңлый иде. Алар янәдән вакытта да, урында да күченделәр. Ярдәмче вәгъдә иткәнчә, инде башлары да әйләнми иде.

...Еракtагы крепость өстеннән куе төтен күтәрелде.

– Нәрсә бу? Без кайда?

– Ә үзегез ничек уйлыйсыз? Без әле һаман сугышның беренче көннәрендә. Сугыш хәрәкәте гадәттә кайда башлана?

– Мөгаен, чик буендадыр?

– Дөрес. Безнең очракта – Советлар Союзының көнбатыш чигендә. Сез бит инде илебезнең элек шулай аталганын беләсездер?


– Алайса, бәлки, бу Брест крепостедыр? – диде Зөләйха. – Минем аның турында укыганым бар.





– Верно. Тот самый год, тот самый день... Мы здесь ненадолго, но вы должны были своими глазами увидеть, как всё начиналось. Потому что фотография ваша из того времени...

Картина перед ними стала расплываться, и путешественники сообразили, что это означает: они снова переместились во времени и в пространстве. Голова, как и обещал ПОмощник, уже не кружилась.



...Вдали над крепостью стоял густой дым.

– Что это? Где мы?

– А сами как думаете? Мы всё ещё в первых днях войны. А где обычно начинаются военные действия?

– Наверное, на границе?

– Правильно. В нашем случае – на западной границе Советского Союза. Вам же известно, что раньше наша страна называлась так?

– Тогда, может быть, это Брестская крепость? – сказала Зулейха. – Я про неё читала.

Гарнизон – шәһәр яки крепостьны шунда яшәп саклый торган солдат һәм офицерлар төркеме.

Гарнизон – группа солдат и офицеров, которая охраняет крепость или город и живёт на их территории.

Казан гарнизоны* дивизияләре сугышның беренче көннәрендә

Дивизии Казанского гарнизона* в первые дни войны

# ТАТАРСТАН – ФРОНТКА



– Нәкъ шулай, – дип раслады Ярдәмче. – Гарнизон сугышның беренче көннәрендә үзеннән күпкә көчлерәк дошман белән батырларча сугышкан. Илебезнең ерак чигендәге ул канлы бәрелешләрдә безнең якташларыбыз да катнашкан.

– Сез Казанда Пётр Гаврилов урамын беләсездер бит? – дип дәвам итте Ярдәмче.

– Беләм, – диде Роман. – Анда минем сыйныфташым яши.

– Менә шул, Брест крепостен батырларча яклап сугышкан хәрбиләрнең берсе – укчылар полкының командиры Пётр Михайлович Гаврилов – Татарстанның Питрәч районында туган. Ул җитәкчелек иткән хәрбиләр төркеме ай буе немецларның тулы бер дивизиясен* тоткарлап тора...

**Дивизия** – берничә частьтан (батальоннардан) торган хәрби подразделение.

**Форт** – крепость яки районның саклану корылмаларының тышкы сызыгы, ныгытма.

Это интересно
Бу кызык



Пётр Гаврилов Брест крепостеның Көнчыгыш фортын* саклау белән җитәкчелек итә. Фортны бомбага тотканнан соң, Гаврилов үз төркеменнән исән калганнар (дүрт пулемётлы 12 сугышчы) белән ай буе оборона тота. 1957 елда ул Советлар Союзы Герое* исеменә лаек була.

Пётр Гаврилов руководил защитой Восточного форта* Брестской крепости. После бомбардировки форта Гаврилов с остатками своей группы (12 бойцами и четырьмя пулемётами) продолжал держать оборону. В 1957 году он был удостоен звания Героя Советского Союза*.

**Советлар Союзы Герое** – зур батырлык кылган кеше.

**Герой Советского Союза** – это человек, который совершил великий подвиг.





– Именно, – подтвердил ПОмощник. – Её гарнизон героически сражался с превосходящими силами противника в первые дни нападения. Причём в этом и в других боях на дальних рубежах участвовали и наши земляки.

– Вы ведь знаете в Казани улицу Петра Гаврилова? – продолжил ПОмощник.

– Конечно, – отозвался Рома. – У меня там одноклассник живёт.

– Так вот, командир стрелкового полка Пётр Михайлович Гаврилов, который родился в Пестречинском районе Татарстана, – один из мужественных защитников Брестской крепости. Группа бойцов под его началом без малого месяц оборонялась едва ли не от целой немецкой дивизии*.



**Форт** – укрепление, часть наружной линии оборонных сооружений крепости или района.

**Дивизия** – военное подразделение, состоящее из нескольких частей (батальонов).

Пётр Гаврилов турында фильм кара

Посмотри фильм о Петре Гаврилове



– Ә Казан үзәгендә шагыйрь Муса Җәлил исемендәге урам бар, – диде Зөләйха. – Безгә дәрестә шагыйрьнең подпольщик* булуы турында сөйләгәннәр иде.

– Әйе, дөрес, – диде Ярдәмче. – Өстәвенә дошманның үз өнендә үк. Җәлил һәм аның иптәшләре, әсирлектә булуларына карамастан, башка тоткыннар белән бергә яшерен оешмага берләшәләр һәм хәрби әсирләрнең Совет армиясе ягына чыгуын, «үлем лагерьлары» әсирләренең качуын әзерлиләр... Алар, фашистларның күп кенә мәкерле ниятләрен җимереп, восстаниегә әзерләнә, ләкин дүрт көн кала фаш ителәләр...

– А в центре Казани есть улица имени поэта Мусы Джалиля, – сказала Зулейха. – Нам на уроке рассказывали, что он был подпольщиком*.

– Да, верно, – сказал ПОмощник. – Причём в самом логове врага. Джалиль и его товарищи, оказавшись в плену, создали там тайную группу и готовили переход военнопленных на сторону Красной армии, побеги узников «лагерей смерти»... Они сорвали немало замыслов фашистов и готовили восстание, но за четыре дня до него были раскрыты...

Подпольщик – фашист илбасарларына каршы көрәшә торган яшерен оешма әгъзасы.

Подпольщик – участник тайной организации, сражающейся с фашистскими захватчиками.

Җәлилчеләр турында укы

Почитай о джалиловцах



Это интересно
Бу кызык



Җәлилчеләр легиондагы* 825 нче батальонның* Белоруссиядә партизаннар* ягына күчүен оештыра. Нәтиҗәдә, тулысынча коралланган 500 дән артык кеше партизан отрядына кушыла һәм аңа камалыштан чыгарга булыша.

Джалиловцы организовали переход в Белоруссии 825-го батальона* легиона* к партизанам*. В результате более 500 человек в полном снаряжении присоединились к партизанскому отряду и помогли ему вырваться из окружения.

**Легион** – бик зур гаскәр.

**Партизан** – дошман басып алган җирләрдә үз иле өчен сугыша торган кеше. Партизаннар еш кына урманнарга яки тауларга кача һәм дошманга шуннан һөҗүм итә.

**Батальон** – берничә йөз солдаттан торган хәрби часть.

**Легион** – очень большое войско.

**Партизаны** – люди, воюющие за свою страну на той её части, которая занята противником. Партизаны нередко скрываются в лесах или горах, откуда и атакуют врага.

**Батальон** – воинская часть, включающая несколько сотен солдат.

Җәлилчеләр турында видео кара
Посмотри видео о джалиловцах

# Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында

# Художники Татарстана о Великой Победе



Әхмәт Китаев 1965 Ахмед Китаев

## МУСА ҖӘЛИЛ МОАБИТ ТӨРМӘСЕНДӘ

Рәссам Әхмәт Китаев зур картиналар ясарга ярата. Аларда еш кына Бөек Ватан сугышы күренешләре чагылыш таба.

Бу картинада татар шагыйре Муса Җәлил сурәтләнгән. Ул сугыш вакытында әсирлеккә алына һәм төрмәгә ябыла. Картинада без бик караңгы һәм шыксыз бүлмә күрәбез. Муса Җәлил ертык зиндан киеменнән, иңбашына пычрак плащ капланган, әмма аның рухы сындырылмаган. Ул бирешми, баш ими! Шагыйрь еракка, яктылыкка карый. Картинаның иң якты элементы – Муса Җәлилнең төрмәдә язган шигырьләр китабы. Бу китап – аның безгә калдырган ядкәре.

## МУСА ДЖАЛИЛЬ В МОАБИТСКОЙ ТЮРЬМЕ

Художник Ахмед Китаев любил писать картины крупных размеров. На них он часто изображал сцены Великой Отечественной войны.

На данной картине изображён татарский поэт Муса Джалиль. Он был взят в плен во время войны и заключён в тюрьму. На картине мы видим очень мрачную, угрюмую и тёмную камеру. Сам Муса Джалиль одет в оборванную тюремную одежду, на плече у него – грязный плащ, но дух его не сломлен. Он не сдаётся! Поэт смотрит вдаль, на свет. Самый яркий элемент картины – книга со стихами, которые Муса Джалиль написал в тюрьме. Это сокровище, которое он оставил всем нам.

«Моабит дәфтәре» фильмын кара




Посмотри фильм «Моабитская тетрадь»

# Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре
# Рисунки детей к юбилею Великой Победы



Станислав Волков рәсеме.
Кайбыч муниципаль районы «Берёзка» Зур Подберезье балалар бакчасы

Рисунок Станислава Волкова.
Большеподберезинский детский сад «Берёзка» Кайбицкого муниципального района



Арсений Пономарёв рәсеме.
Алабуга муниципаль районы 29 нчы «Алтын балык» катнаш төрдәге балалар бакчасы

Рисунок Арсения Пономарёва.
Детский сад комбинированного вида №29 «Золотая рыбка» Елабужского муниципального района

# Өченче бүлек. «Пешкабыз ферзьгә әйләнә»

– Ә хәзер тылга* кайтыйк… Мине заманында ничек дип атап йөрткәннәрен беләсезме? – дип сорады Ярдәмче.

Һәм шунда Рома белән Зөләйха үзләренең По-2 самолётында кукуруз басуы өстеннән очып баруларын күрделәр.

– Ничек?

– «Кукурузник».

– Ник алай?

– Чөнки минем кебекләр башта авыл хуҗалыгына булышканнар: кырларга ашлама яисә зарарлы бөҗәкләргә каршы кулланыла торган матдәләр сипкәннәр…

Романың кесәсендә кинәт телефон шалтырады.

– Кара әле, эшли бит бу! – диде ул, гаҗәпләнеп.

– Ә нигә әле эшләмәскә тиеш ул? – диде Ярдәмче. – Әниең синең өчен борчыладыр, мөгаен.

Бу әнисе түгел, ә фотограф Вова дәдәй иде.

– Рома! Мин монда синең файлың белән утырдым әле. Һәм анда тоныкланып, югалып беткән язма таптым!

– Нәрсә язылган?

– Аста – «Казан, 1945». Ә өстәрәк тагын ике юл бар, беренчесен мин әле укый алмадым, ә икенчесендә «Васяга Ринат дустыннан» дип язылган. Син берәр нәрсә аңлыйсыңмы?

– Ю-юк… – диде югалып калган Рома.

– Я, уйлап кара әле…

– Рәхмәт! Уйлап карармын! Әгәр берәр нәрсә ачыкланса, шалтыратыгыз!

– Сөйләштек, – диде Вова дәдәй, һәм элемтә өзелде.



Тыл – сугыш барган илнең фронт сызыгы артындагы территориясе.

# Глава третья. «Наша пешка выходит в ферзи»

– А сейчас вернёмся в тыл*... Знаете, как меня когда-то называли? – спросил ПОмощник.

Тут Рома и Зулейха обнаружили, что летят на По-2 над кукурузным полем.

– Как?

– «Кукурузник».

– Почему?

– Потому что такие, как я, помогали сельскому хозяйству: распыляли над полями удобрения или вещества для борьбы с вредными насекомыми...



У Ромы в кармане вдруг зазвонил сотовый телефон.

– Гляди-ка, работает! – удивился хозяин.

– А почему бы нет? – сказал ПОмощник. – Мама, наверно, беспокоится...

Это была не мама, а фотограф дядя Вова:

– Рома! Я тут попробовал кое-что с твоим файлом сделать. И нашёл стёртую надпись!

– Какую надпись?

– Внизу «Казань, 1945». А повыше ещё две строчки, первую я пока не разобрал, а вторая – «Васе от друга Рината». Тебе это о чём-нибудь говорит?

– Н-нет... – растерянно сказал Рома.

– Ну, подумай ещё...

– Спасибо, дядя Вова! Подумаю! Вы, если что, звоните!

– Ладушки. – И дядя Вова отключился.

**Тыл** – территория воюющей страны, находящаяся позади линии фронта.

Казан – хезмәт батырлыгы шәһәре

Казань – город трудовой доблести



Казан вертолёт заводының
Хезмәт даны музее

Музей трудовой славы
Казанского вертолётного завода

Это интересно

Бу кызык

1943–1944 елларда илебездә самолётлар фашист Германиясендәгедән җиде тапкыр күбрәк җыела. Бөек Ватан сугышы елларында СССР авиация сәнәгате җитештергән барлык самолётларның һәр унынчысы Казан вертолёт заводында чыга.

В 1943–1944 годах самолётов в стране производилось в семь раз больше, чем в гитлеровской Германии. На Казанском вертолётном заводе был собран каждый десятый самолёт из всех выпущенных авиационной промышленностью СССР за годы Великой Отечественной войны.



– Килеп җиттек, – диде Ярдәмче. – Самолётны күрәсезме? Ул вакытта мин менә шундый идем. Бу вертолёт заводы, По-2 очкычларының туган йорты. Шунысын да әйтим: канатларыбыз агачтан безнең. Вертолёт заводы ул елларда агачтан әрҗәләр, тәгәрмәчләр, канатлар, кыш көне очып китү һәм төшеп утыру өчен чаңгылар ясаган. Ә 1941 елның җәй азагында өйрәнчек самолётлар чыгара башлый.

– ...Всё, добрались, – сказал ПОмощник. – Видите самолёт? Вот так я тогда выглядел. Это вертолётный завод, откуда По-2 родом. Крылья у нас, между прочим, деревянные. Вертолётный завод выпускал в те времена ящики, колёса, крылья, лыжи для взлёта и посадки зимой. А в конце лета 1941 года стал делать учебные самолёты.

Это интересно / Бу кызык

Сугыш елларында республикабызда 21 меңнән артык самолёт (шулардан 10 меңнән артыгы – Пе-2 бомбардировщигы; 79 ы – Пе-8 бомбардировщигы; 11 553 е – По-2 самолёты) һәм 16 мең авиация моторы җитештерелгән.

За годы войны в нашей республике было произведено более 21 тысячи самолётов (из них более 10 тысяч – пикирующие бомбардировщики Пе-2; 79 – бомбардировщики Пе-8; 11 553 – самолёты По-2) и около 16 тысяч авиационных моторов.

Пе-2 турында документаль фильм

Документальный фильм о Пе-2

– Ә анда кемнәр эшләгән соң? Ир-атларның, мөгаен, күбесе фронтка киткәндер...

– Ул чакта цехларда бар эшне өлкән яшьтәгеләр, хатын-кызлар, яшүсмерләр башкарган. Алар көн-төн диярлек эшләгәннәр, хәтта заводта ашаганнар һәм кунып та калганнар. Тиздән разведка өчен дә, элемтә чарасы буларак та кирәкле беренче агач У-2 самолётлары эшләп чыгарганнар. Ә тагын әле самолётның канатларына беркетелгән махсус капсулаларда алгы сызыктан яралы сугышчыларны алып чыкканнар.

– А кто же на нём работал? Ведь мужчины, наверное, в основном на фронт ушли...

– В цехах всю работу выполняли пожилые люди, женщины и подростки. Трудились они почти круглые сутки, даже ели и спали на заводе. Зато скоро были готовы первые деревянные самолёты У-2, нужные и для разведки, и как средство связи. А ещё на них – в особых капсулах, крепившихся к крыльям, – вывозили с передовой раненых.

Стапель – судно һәм самолётлар төзү яки ремонтлау өчен кирәкле конструкция.

Стапель – конструкция, на которой строят или ремонтируют суда и самолёты.

Это интересно

Бу кызык

1942 ел Казан авиазаводы үсешендә борылыш елы була: продукция күләме, 1940 ел белән чагыштырганда, сигез тапкырга арта. Иң югары күрсәткечләргә ул 1944 елда ирешә. Һәр тәүлек стапельләрдән* 10–12 Пе-2 самолёты төшә (ә барлыгы ун меңнән артык шундый очкыч чыгарыла).

Переломным в развитии Казанского авиазавода №22 стал 1942 год: объём продукции вырос по сравнению с 1940 годом в восемь раз. Наивысших показателей достигли в 1944 году. Каждые сутки со стапелей* сходили по 10–12 самолётов Пе-2 (а всего их было выпущено более десяти тысяч).

По-2 самолёты турында фильм кара

Посмотри фильм о самолёте По-2



По-2 самолёты (1944 елга кадәр – У-2):

- Буш өйрәнчек самолётның авырлыгы – 656 кг.
- Максималь тизлеге – сәгатенә 130–150 км.
- Тизләнеп очып китү өчен 15 метр ара җитә.
- У-2ВС моделе 8 кг авырлыктагы 6 бомба ташый ала, мондый самолётның арткы кабинасында пулемёт урнаштырылган ату ноктасы була.
- Немецлар әлеге совет самолётларын мотор тавышы аркасында «кофетарткыч» һәм «тегү машинасы» дип йөртә.
- У-2 самолёты пилотлары гадәттә хатын-кызлар була. Шулардан 23 очучы хатын-кызга Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Самолёт По-2 (до 1944 года – У-2):

- Вес пустого учебного самолёта – 656 кг.
- Максимальная скорость – 130–150 км/ч.
- Для разбега необходимо не более 15 метров.
- Модель У-2ВС могла брать на борт 6 бомб весом 8 кг, в задней кабине такого самолёта находилась стрелковая точка с пулемётом.
- Немцы называли эти советские самолёты «кофемолка» и «швейная машина» из-за звука мотора.
- Пилотами У-2 обычно были девушки. 23 лётчицам, воевавшим на самолётах У-2, было присвоено звание Героя Советского Союза.

Кечкенә, әле җитмәсә, агач канатлы бу самолётларга дошманнар башта әллә ни җитди карамый, аларны «рус фанеркасы» дип йөртәләр. Тик аннары У-2 очкычының бик манёврлы*, ягъни җитез булуы һәм катлаулы виражлар* башкара алуы ачыклана. Завод җиңел моторлы бомбардировщиклар да чыгара башлый.

– Ә ни өчен алар У-2, ә сез По-2? – дип сорады Зөләйха. – Алар белән кем идарә иткән соң?

– Мине соңрак конструктор Николай Николаевич Поликарпов хөрмәтенә По-2 дип атаганнар. Ә очучылар гадәттә кызлар булган. Алар арасында Ольга Санфирова һәм Мәгубә Сыртлановага Советлар Союзы Герое исеме бирелгән. Дошманнар очучы кызларны «төнге пәриләр» дип атап йөрткәннәр һәм алардан бик курыкканнар: караңгыда По-2 дошманнарга тавышсыз гына якынайган һәм бомбалар ташлаган. Дошманнар, ут ачып, үз урыннарын белдерүгә, башка бомбардировщиклар, килеп, көчле удар ясаганнар.

К небольшим самолётам, да ещё с деревянными крыльями, враги поначалу серьёзно не относились, звали их «русской фанеркой». Но выяснилось, что У-2 очень манёвренные*, то есть ловкие, и могут выполнять сложные виражи*. Завод начал выпускать легкомоторные бомбардировщики.

– А почему они У-2, а вы По-2? – спросила Зулейха. – И кто ими управлял?

– По-2 меня назвали позже, в честь конструктора Николая Николаевича Поликарпова. А пилотами обычно были девушки. И среди них Ольга Санфирова и Магуба Сыртланова, которые удостоены звания Героя Советского Союза. Враги прозвали лётчиц «ночными ведьмами» и очень их опасались: в темноте По-2 бесшумно подлетали к неприятелю и сбрасывали бомбы. Враги начинали стрелять, выдавая себя, и получали мощный ответный удар: появлялись другие бомбардировщики.

Манёвр – оста хәрәкәт, борылыш.

Манёврлы – хәрәкәтчән, юнәлешен тиз үзгәртергә сәләтле.

Вираж – юлда машинаның яки һавада самолётның кискен һәм тиз борылуы.


Манёвр – ловкое действие, приём.


Манёвренный – подвижный, способный быстро менять направление движения.

Вираж – резкий, быстрый поворот машины на дороге или самолёта в небе.

Мәгубә Сыртланова турында видеолар кара

Посмотри видео о Магубе Сыртлановой





Это интересно / Бу кызык

По-2 самолётына аның конструкторы Николай Поликарпов хөрмәтенә шундый исем бирелә.

Самолёт По-2 назвали в честь его конструктора – Николая Поликарпова.


Это интересно / Бу кызык

1 миллион 270 мең – сугыш елларында совет очучылары шулкадәр хәрби очыш ясаган, шуларның 660 меңе – По-2 самолётларында. Шулай итеп, очышларның яртысы Казанда эшләнгән По-2 очкычында башкарылган.

1 миллион 270 тысяч боевых вылетов сделали пилоты страны за годы войны, из которых 660 тысяч – на самолётах По-2. То есть половина вылетов была выполнена на По-2, изготовленных в Казани.

По-2 турында видео кара

Посмотри видео о По-2




Пе-8 турында видео кара

Посмотри видео о Пе-8

Это интересно

Бу кызык

- 1941–1945 елларда завод ун меңнән артык самолёт чыгара, алар Хәрби-һава көчләренең төп бомбардировщикларына әйләнә.
- Пе-8, инде 1941 елның июлендә үк Германиягә барып җитеп, Берлинны бомбага тоткан беренче самолёт була.
- Пе-2 һәм Пе-8 дошманны Мәскәү һәм Сталинград янында, Курск дугасында бомбага тота, Берлинны штурмлауда катнашалар.

- В 1941–1945 годах заводом было выпущено больше десяти тысяч самолётов, ставших основными бомбардировщиками Военно-воздушных сил страны.
- Пе-8 был первым самолётом, который уже в июле 1941 года долетел до Германии и сбросил бомбы на Берлин.
- Пе-2 и Пе-8 громили врага под Москвой и под Сталинградом, на Курской дуге, участвовали в штурме Берлина.

– Сүз уңаеннан, – дип өстәде Ярдәмче, – фотограф Виктор Тёмин Берлинның төп бинасы – рейхстагка беркетелгән Җиңү байрагының атаклы фотографиясен 1945 елның беренче маенда нәкъ менә По-2 бортыннан төшереп ала... Ләкин безгә инде башка заводка – Казан авиация заводына барырга вакыт.

Һәм Роман белән Зөләйха Ярдәмче белән бергә инде гадәтләнгәнчә башка урынга күчеп тә куйдылар. Ә Ярдәмче сүзен дәвам итте:

– Безнең авиация заводы сугышның беренче көннәреннән үк тәүлек әйләнәсе эшли башлый. Ул Пе-2 һәм Пе-8 самолётларын чыгара.

– «Пе» атамасы да конструктор исеменнән алынганмы? – диде инде төшенгән Зөләйха.

– Әйе. Владимир Михайлович Петляковтан. Ә самолётлар бомбардировщиклар була. Пе-2 – ике, ә Пе-8 – дүрт моторлы. Пе-8 биектән оча ала, шактый яхшы җиһазландырылган һәм коралланган була.

– Между прочим, – добавил ПОмощник, – именно с борта По-2 фотограф Виктор Тёмин 1 мая 1945 года сделал знаменитую фотографию Знамени Победы над главным зданием Берлина, рейхстагом... Но нам уже пора на другой завод – Казанский авиационный.

И ребята вместе с ПОмощником уже в привычном режиме переместились. А он продолжил:

– Наш авиационный завод с первого дня войны работал круглосуточно. А выпускал он самолёты Пе-2 и Пе-8.

– Пе – это тоже по имени конструктора? – догадалась Зулейха.

– Да. В честь Владимира Михайловича Петлякова. А самолёты были бомбардировщиками: Пе-2 – двух-, а Пе-8 – четырёхмоторным. Пе-8 мог летать на больших высотах и был отлично оборудован и вооружён.

Это интересно / Бу кызык




Пе-2 һәм Пе-8 самолётлары конструктор Владимир Петляков хөрмәтенә аталган.

Самолёты Пе-2 и Пе-8 названы в честь конструктора Владимира Петлякова.



– Тәҗрибәле очучы самолётын автомобиль йөртүче үз машинасын яраткан кебек ярата, дия иде минем бабай, – диде Рома.

– Әлбәттә, – диде Ярдәмче. – Алар өчен ул техника гына түгел, ә һәрвакыт ярдәмгә килә торган тугры дус та бит. Очучылар бу самолётны яратып «Пешка» дип йөртә, ә аны җитди рәвештә камилләштергән очракта, мәсәлән, тизлеген арттыргач: «Безнең пешка ферзьгә әйләнә», – дип шаярталар (пешка, ферзь – шахмат фигуралары).



– Мой дедушка говорил, – сказал Рома, – что опытный лётчик любит свой самолёт, как водитель надёжного автомобиля – свою машину.

– Это понятно, – согласился ПОмощник. – Для них самолёт не просто техника, а верный друг, который всегда выручит. Не зря пилоты ласково звали этот самолёт «Пешкой». А когда его удавалось серьёзно усовершенствовать, например увеличить скорость, шутили: «Наша пешка выдвигается в ферзи» (пешка, ферзь – шахматные фигуры).




1943 елның октябрендә А. Г. Васильченко С. П. Королёв уйлап тапкан реактив тизләткечле Пе-2 самолётын сыный. Бүген Казанның Мәскәү районында А. Васильченко урамы бар.

А. Г. Васильченко испытывал в октябре 1943 года самолёт Пе-2 с реактивным ускорителем С. П. Королёва.
Сегодня в Московском районе Казани есть улица А. Васильченко.

– Балалар, без заводтан киткәнче, миңа әйтегез әле: теләсә кайсы машинада – җирдә йөри торганында да, суда йөзә яки һавада оча торганында да – нәрсә булырга тиеш?

– Руль? Көпчәкләрме?

– Тагын? Иң мөһиме?

– Ә-ә! Мотор!

– Нәкъ шулай. Һәм менә хәзер без, – Ярдәмче янә кучу өчен пауза ясап алды, – Казан моторлар төзү заводында. Сугышка кадәр монда По-2 самолётлары двигательләре өчен аерым узеллар* чыгарылган. Игътибар белән тыңлыйбыз!

Рома белән Зөләйхага гүләгән тавыш (гүя якында гына станоклар эшли башлады) һәм дулкынланып әйтелгән сүзләр ишетелде: «Ишетәсезме? Бу безнең көч, безнең куәт гөрелтесе! Фашистлар бу тавышны беркайчан да онытмасыннар! Совет халкының нәрсәгә сәләтле булуын белсеннәр!»

– Нәрсә бу? Кем сөйли моны?

– Бу – 1945 елның 9 маена каршы төндә завод директоры Макар Лукин сөйләгән сүзләр. Ул, фашистлар Германиясенең тулы капитуляциясе* турында алданрак ишетеп, заводка килә һәм Җиңү митингы оештыра. Һәм сынау стендларындагы барлык двигательләрне иң көчле режимда кушып җибәрергә боера... Әмма 1941 елда бу мизгелгә әле ерак була. Фронт двигательләр сорый. Кешеләр тәүлегенә 12–16 шар сәгать эшли. Эшчеләр планны һәрвакыт арттырып үти. Барысы да фронт өчен! Барысы да Җиңү өчен!

**Узел** – бергә тоташтырылган детальләр, техник җайланма яки машинаның мөһим өлеше.

**Капитуляция** – җиңүче як шартларында сугыш хәрәкәтләрен туктату.



Это интересно

Бу кызык

1941 елдан 1945 елга кадәр 18 126 мотор җыела, бу әлеге типтагы барлык моторларның яртысын тәшкил итә. Завод конвейерыннан илле минут саен әзер двигатель төшеп тора. Завод музеенда сирәк экспонат – сугыш елларында чыгарылып, бүген авыр хезмәт һәм героизм чоры һәйкәленә әйләнгән двигатель саклана.

Хезмәт батырлыгы предприятиесе

Предприятие трудовой доблести

– А пока мы не покинули завод, скажите-ка мне, ребята, что непременно должно быть у любой машины – и сухопутной, и водной, и воздушной?

– Колёса? Руль?

– А ещё? Самое важное?

– А-а! Мотор!

– Точно. И сейчас мы, – ПОмощник сделал паузу для очередного перемещения, – на Казанском моторостроительном заводе. До войны здесь выпускались отдельные узлы* для двигателей самолётов По-2. Слушаем внимательно!


До ребят донёсся гул – как будто неподалёку заработали станки – и пробивающийся сквозь него взволнованный голос: «Вы слышите? Это гремит наша сила, наша мощь! Пусть этот гул никогда не забудут фашисты! Пусть знают они, на что способен советский народ!»

– Что это? Кто это говорит?

– Это речь директора завода, Макара Лукина, в ночь на 9 мая 1945 года. Он, уже зная о капитуляции* фашистской Германии, приехал на завод, организовал митинг, посвящённый Победе, и приказал запустить на самый громкий режим изделия на испытательных стендах... Но в 1941 году до этого момента было далеко. Фронт требовал двигателей. Люди трудились по 12–16 часов в сутки. Рабочие всегда перевыполняли план. Всё – для фронта, всё – для Победы!

Узел – соединение деталей, важная часть технического устройства или машины.

Капитуляция – прекращение военных действий на условиях победителя.



Это интересно

Бу кызык

С 1941 по 1945 год было собрано 18 126 моторов, что составляет половину всех собранных моторов этого типа. Готовый двигатель с заводского конвейера сходил каждые пятьдесят минут. В музее завода хранится редкий экспонат – двигатель, выпущенный в годы войны и ставший сегодня своего рода памятником тому трудному и героическому времени.

Казан моторлар төзү берләшмәсе сугыш елларында

Казанское моторостроительное объединение в годы войны

# Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында
# Художники Татарстана о Великой Победе



Лотфулла Фәттахов

1971–1975

## КОЛЯ КУРИЦЫН – ПОЛК УЛЫ

Солдатлар үз тәрбияләренә алган баланы «полк улы» дип атаганнар. Ул, солдатлар белән яшәп, хәрби эшкә өйрәнгән һәм төрлечә ярдәм итәргә тырышкан.

Картинада без нәкъ шундый бала – «полк улы»н күрәбез. Ул хәрбиләрчә киенгән, иңбашына корал аскан, кулында – йөк машиналарының (алар картинаның арткы планында күренә) хәрәкәтен көйләү өчен кечкенә флаглар. Малай әле үсмер генә, ләкин инде бик кыю. Ул бернәрсәдән дә курыкмый кебек. Полк улы җиңәчәгебезгә ышана һәм Җиңүне якынайтырга тырыша.

Лотфулла Фаттахов

## КОЛЯ КУРИЦЫН – СЫН ПОЛКА


«Сыном полка» называли ребёнка, которого взяли на воспитание солдаты. Он жил с ними, учился военному делу и всячески старался помочь.

На картине мы видим как раз такого ребёнка – «сына полка». Он одет по-военному, на плече у него – оружие, в руках – флажки для регулирования движения грузовиков (они видны на заднем плане картины). Он ещё совсем юный, но уже очень решительный. Он словно ничего не боится, ему ничто не страшно. Он уверен в нашей победе и старается приблизить её.

Сугыш ветераны булган рәссам Л. Фәттахов турында укы

Почитай о художнике – ветеране войны Л. Фаттахове

# Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре
# Рисунки детей к юбилею Великой Победы



Милослав Оловянников рәсеме.
Казан шәһәре Идел буе районының катнаш төрдәге 242 нче балалар бакчасы


Рисунок Милослава Оловянникова.
Детский сад №242 комбинированного вида Приволжского района города Казани




Мәрьям Мөхетдинова рәсеме.
Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре 10 нчы номерлы «Ромашка» һәрьяктан үстерешле балалар бакчасы

Рисунок Марьям Мухетдиновой.
Детский сад общеразвивающего вида № 10 «Ромашка» города Кукмор Кукморского муниципального района





Атаклы «катюша»
Знаменитая «катюша»

# Дүртенче бүлек. Җирдә дә, суда да

– Әмин тагын нәрсәсез сугыш алып барып булмаганын беләм, – диде кинәт уйга калган Рома.

– Нәрсәсез инде ул? – Ярдәмче бер дә гаҗәпләнмәде бугай.

– Дарысыз!

– Дөрес. Казаныбызның дары заводында сугыш елларында дары да, башка сугыш кирәк-яраклары да ясаганнар. 1941 елның азагында завод легендар «катюша» өчен Казанның яшерен лабораторияләрендә галимнәр тарафыннан уйлап табылган яңа төр дары чыгара башлый. Ә «катюша»лар, билгеле булганча, җиңүдә бик мөһим роль уйнаган.

– Сугыш бит җирдә һәм күктә генә түгел, ә суда – диңгездә, елгаларда да барган, – диде Зөләйха. – Ул вакытта кораблар да төзегәннәрдер, дип уйлыйм.

– Син хаклы. Корабларның берсен без хәзер күрербез дә...

# Глава четвёртая. На суше и на море

– А я знаю, без чего ещё нельзя воевать, – сказал вдруг Рома.

– И без чего же? – ПОмощник даже не удивился.

– Без пороха!

– Верно. У нас в Казани на пороховом заводе в годы войны делали и порох, и другие боеприпасы. Но в конце 1941 года завод уже начал выпускать новый вид пороха для легендарных «катюш», созданный учёными в секретных казанских лабораториях. А «катюши», как известно, сыграли очень важную роль в общей победе.

– Но война же шла не только на суше и в небе, но и на воде – на море, на реках, – сказала Зулейха. – Наверняка тогда строили и много кораблей…

– Да, и один из них мы сейчас увидим…







Казан дары заводы сугыш елларында 100 мең тоннадан артык дары, миномётлар (шул исәптән «катюша»ларга реактив дарылы зарядлар), шулай ук диңгез артиллериясе, самолёт кораллары, танкка каршы һәм зенит системалары өчен 30 миллионнан артык заряд җитештергән.

Казанский пороховой завод за годы войны изготовил больше 100 тысяч тонн пороха, более 30 миллионов зарядов к миномётам, в том числе с реактивным порохом для «катюш», а также для морской артиллерии, для противотанковых, зенитных и самолётных систем.

Казан дары заводы турында видео кара

Посмотри видео о Казанском пороховом заводе





Бронекатерлар*, коры җир гаскәрләренә ярдәм итеп, елгаларда сугыша. Сугыш елларында мондый типтагы 77 судно суга төшерелә. Бу, әйтик, Идел флотилиясен тулысынча яңадан җиһазларга мөмкинлек бирә. «Елга танклары» Сталинград сугышында мөһим удар көчне тәшкил итә.

Бронекатера* сражались на реках, помогая сухопутным войскам. За годы войны на воду было спущено 77 судов этого типа. Это позволило, например, полностью перевооружить Волжскую флотилию. «Речные танки» стали её важной ударной силой в Сталинградской битве.

Бронекатер – броня белән ныгытылган хәрби кораб.

Бронекатер – военный корабль, защищённый бронёй.

Һәм сәяхәтчеләр шунда ук яр буена килеп чыкты. Елга буйлап әллә ни зур булмаган, ләкин ныклыгы күзгә ташланып торган судно бара иде.

– Бу бронекатер, – дип аңлатты Ярдәмче. – Ул вакытта Яшел Үзәннең 340 нчы заводында эшләнгән корабларның берсе. Завод су асты көймәләрен аулый торган кораблар, диңгез буксирлары*, торпеда катерлары, тральщиклар* төзи, авиабомба корпуслары, зенит җайланмалары, аэрочаналар, снарядлар һәм пулемётлар ясый. Бронекатерларны «елга танклары» дип атап йөртәләр, ә сугышчылар кайчак «үгезбозаулар» дип атыйлар. Бу кораблар яшелүзәнлеләрнең иң танылган хәрби техникасы төренә әверелә.

Это интересно
Бу кызык

Илдә барлыгы 308 бронекатер төзелә, шуларның 148 е – Яшел Үзәндә. Бу судноларның батырлыгын мәңгеләштереп, завод территориясенә кергән җирдә пьедесталга борт номеры 234 булган «Калюжный» катеры куелган.

Всего в стране было построено 308 бронекатеров, из которых 148 – в Зеленодольске. Память о подвиге этих судов увековечена: перед входом на территорию завода на пьедестале установлен катер «Калюжный» с бортовым номером 234.

Вдруг путешественники оказались на берегу, вдоль которого двигалось какое-то не слишком большое, но явно крепкое судно.

– Это бронекатер, – пояснил голос ПОмощника. – Один из тех, которые тогда делал Зеленодольский завод №340. Ещё он строил корабли-охотники за подводными лодками, морские буксиры*, торпедные катера, тральщики*, изготавливал корпуса авиабомб, аэросани, зенитные установки, снаряды и пулемёты. Бронекатера (их называли «речными танками», а бойцы иногда – просто «бычками») стали самым знаменитым видом военной техники, выпускаемой зеленодольцами.

Буксир – башка корабларга яки йөзмә корылмаларга хәрәкәт итәргә булыша торган үзйөрешле судно.

Тральщик – башка кораблар куркынычсыз йөзә алсын өчен, суда миналарны эзли һәм юк итә торган кораб.

Буксир – самоходное судно, помогающее двигаться другим судам или плавучим сооружениям.

Тральщик – корабль, который находит и уничтожает мины в воде, чтобы другие суда могли плавать безопасно.



– 62 нче армия командующие В. Чуйков соңрак, «елга танклары»н ясаучыларга мөрәҗәгать итеп, болай дип яза: «Әгәр сезнең «үгезбозаулар» булмаса, без позицияләребезне саклап кала алмас идек. Идел ярлары арасында йөргән катерлар ярдәмендә без ун көнгә җитәрлек корал, сугыш кирәк-яраклары, азык-төлек, медикаментларны китереп җиткерә алдык һәм, һөҗүм артыннан һөҗүм ясап, Сталинградны дошманга бирмәдек...»

– Хәзер инде безгә китәргә вакыт...

– Туктагыз әле! – дип кычкырып җибәрде Рома. – Командирның исеме ничек дидегез?

– Чуйковмы? Василий Иванович.

– Әйе! Менә хәзер миңа барып җитте! Минем бабам Васильевич, димәк, аның әтисенең исеме Василий булган! Вася!


– Чормадагы теге фотографияне аңа бүләк иткән булганнар, дип уйлыйсыңмы? – дип сорады Зөләйха.

– Әйе инде!

– Серне ачуга тагын бер адым ясалды кебек, – диде Ярдәмче. – Шәп бу. Тик без килеп тә җиттек инде...

Бик тиздән сәяхәтчеләребез икенче бер завод алдында торалар иде.

– Ә монда нәрсә ясыйлар? Дөресрәге, нәрсә ясаганнар?







Василий Иванович Чуйков

Позднее в своей книге, обращаясь к создателям «речных танков», командующий 62-й армией Василий Иванович Чуйков написал: «Если бы не ваши «бычки», нам бы не удержать тогда позиций. Благодаря катерам, курсировавшим между берегами Волги, мы смогли доставить десятидневный запас вооружения, боеприпасов, продовольствия, медикаментов и успешно отстояли Сталинград...»

– А теперь нам пора... – сказал ПОмощник.

– Погодите! – вдруг закричал Рома. – Ещё раз: как этого командира звали?

– Чуйкова? Василий Иванович.

– Точно! До меня дошло! У моего дедушки отчество – Васильевич, значит, моего прадеда звали Василием! Васей!


– Думаешь, это ему снимок с чердака подарили? – спросила Зулейха.

– Ну да!

– Похоже, сделан ещё шаг к разгадке, – сказал ПОмощник. – Это здорово. Но мы уже на месте...

И перед путешественниками появился другой завод. Хотя, скорее, это они вместе с ПОмощником возникли перед ним.

– А здесь что делают? Точнее, делали.




Казан электр техникасы заводы турында видео кара

Посмотри видео о Казанском электротехническом заводе

– Күп нәрсәләр. Мәсәлән, махсус «күзәтү торбасы»ның өлешләрен, – диде Ярдәмче. – Аның детальләрен Казанда 1941 елның сентябрендә ясый башлыйлар. Бу электр техникасы заводын бирегә Ленинградтан күчерәләр. Ә бу «торба» үзе «артиллерия зенит уты белән идарә итү приборы» дип атала, кыскача – ПУАЗО («прибор управления артиллерийским зенитным огнём»).

– ПУАЗО? Туктагыз әле... – диде Рома. – Бабам миңа аның турында сөйләгән иде бит! Кызыклы да, исеме дә бераз көлке булганга, ул хәтеремдә калган.

– Нәрсәләр хәтерлисең?

– Кыскасы, сугышчылар окулярлар аша самолётларны күзәтә. Самолётның өстәрәкме әллә астарακмы, уңдаракмы әллә сулдаракмы булуын һәм теге ни... ераклыгын карый, менә шул!

– Ераклыгынмы? – дип, кайтарып сорады Зөләйха. – Ничек була инде ул?

– Ягъни самолётның алардан никадәр ераклыкта булуын билгелиләр. «Торба» шунда ук зениткаларга самолётның кайда икәнен хәбәр итә.

– Син безнең белгеч икән бит! – диде Ярдәмче. Һәм өстәп куйды: – Электр техникасы заводы диңгез кораблары өчен дә, соңрак самолётлар өчен дә приборлар чыгарган.

– Много чего. Например, части особой «подзорной трубы», – сказал ПОмощник. – Детали для неё в Казани в сентябре 1941 года начали изготавливать. Сам этот завод, электротехнический, сюда из Ленинграда перевезли. А вся «труба» очень непростая и называется «прибор управления артиллерийским зенитным огнём», сокращённо – ПУАЗО.

– ПУАЗО? Погодите-ка... – сказал Рома. – Мне же дедушка про это рассказывал! Только он служил намного позже. Я запомнил, потому что интересно и слово немножко смешное.

– И что ты помнишь?

– В общем, там бойцы за самолётами следят. Выше самолёт или ниже, правее или левее, и по этой... по дальности, вот!

– По дальности? – переспросила Зулейха. – Это как?

– Ну то есть определяют, насколько далеко от них самолёт. И «труба» сообщает на зенитки, где цель.

– Да ты у нас знаток! – сказал ПОмощник. И добавил: – Электротехнический завод выпускал и приборы для морских судов, а позже – и для самолётов.

# Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында
# Художники Татарстана о Великой Победе



1946

Мәхмүт Усманов

## СОВЕТ АРТИЛЛЕРИЯСЕ УТЫ АСТЫНДА

Татарстан АССРның халык рәссамы, Бөек Ватан сугышында катнашкан кылкаләм иясе Мәхмүт Усмановның «Совет артиллериясе уты астында» картинасында без яу кырын күрәбез. Күк йөзе бөтенләй күренми: дошман өстенә ут яудыру аркасында, тирә-як тузанга, туфракка баткан. Картинадагы танкның авыр башнясы снаряд эләгүдән өзелеп төшкән. Алгы планда сурәтләнгән фашист, коралын ташлап, сугыш кырыннан качып котылырга тырыша.

Рәссам Бөек Җиңү юлында артиллерия гаскәрләренең ролен ачык күрсәтә. Ул безнең куәтле гаскәрләребезгә дошманнар да, аларның техникасы да каршы тора алмаячагына басым ясый.

Махмуд Усманов

## ПОД ОГНЁМ СОВЕТСКОЙ АРТИЛЛЕРИИ

На картине народного художника Татарской АССР, участника Великой Отечественной войны Махмута Усманова «Под огнём советской артиллерии» мы видим поле боя. Небо совсем не видно: всё вокруг в пыли и дыму от ударов по врагу. От попадания снаряда у танка на картине сорвало тяжёлую башню. Фашист, изображённый на переднем плане, бросил своё оружие и в панике пытается спастись бегством с поля боя.

Художник ярко показал роль артиллерийских войск на пути к Великой Победе. Он подчеркнул, что перед нашей мощью не устоят ни враги, ни их техника.

# Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре
# Рисунки детей к юбилею Великой Победы




Бәхтияр Гыйльманов рәсеме.
Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе «Берёзка» балалар бакчасы

Рисунок Бахтияра Гильманова.
Рыбно-Слободский детский сад «Берёзка» Рыбно-Слободского муниципального района




Ролан Зинәтуллин рәсеме.
Нурлат шәһәре балаларны һәрьяклап үстерү төрендәге 5 нче номерлы «Камыр Батыр» балалар бакчасы

Рисунок Ролана Зинатуллина.
Детский сад №5 «Камыр Батыр» общеразвивающего вида города Нурлат



# Бишенче бүлек. Барысы да фронт өчен

– Ә лек тыныч тормыш өчен кирәк-яраклар чыгарган завод һәм фабрикалар сугыш вакытында нәрсәләр җитештерә?

– Һәркайсына хәрби заказ тапшырыла. Казан киноплёнка фабрикасы, мәсәлән, дошманның хәрби объектларын фотога төшерү өчен авиация плёнкасы чыгара башлый. Язу машинкалары, ясалма күн, автогараж җиһазлары заводлары, сугыш башлангач, мина, снаряд, яктырткыч бомбалар җитештерергә тиеш була.

– Ә сәгатьләрне, мәсәлән, кем җитештергән? Алар да фронтта кирәк булган бит, – диде Рома. – Әйтик, уртак хәрәкәтләр алдыннан вакытны билгеләү өчен.

– Дөрес уйлыйсың. Аларны Чистайда ясыйлар, анда 1941 ел ахырында 2 нче Мәскәү сәгать заводы эвакуацияләнә, ә инде өч айдан завод продукциянең беренче партиясен чыгара.

# Глава пятая. Всё для фронта

– А что во время войны выпускали заводы и фабрики, которые раньше только мирную продукцию делали?

– Всем им были поручены военные заказы. Казанская фабрика киноплёнки давала армии авиационную плёнку для фотографирования военных объектов противника. Заводы пишущих машин, искусственной кожи, автогаражного оборудования изготавливали мины, снаряды, осветительные бомбы.



– А часы, например? Они ведь на фронте тоже нужны, – сказал Рома. – Чтобы сверять время перед общими действиями.

– Правильно рассуждаешь. Их делали в Чистополе, куда в конце 1941 года эвакуировался 2-й Московский часовой завод, а уже через три месяца завод выпустил первую партию продукции.



Это интересно
Бу кызык

Казан мех комбинаты кыска туннар, колакчынлы бүрекләр, бияләйләр, жилетлар, итекләр, очучылар өчен комбинезоннар һәм шлемофоннар*, җылы эчке киемнәр тегә. «Спартак» комбинаты да армия өчен күпләп аяк киемнәре җитештерүгә күчә: сугышның беренче елында гына да анда миллионлаган совет сугышчысына аяк киеме тегелә.

Казанский меховой комбинат шил полушубки, шапки-ушанки, рукавицы, жилеты, унты, комбинезоны и шлемофоны* для лётчиков, тёплое бельё. На массовый выпуск армейской обуви перешёл комбинат «Спартак»: только за первый год войны он сделал обувь для миллиона бойцов Красной армии.

Шлемофон – колакчынлы һәм микрофонлы шлем. Командаларны ишетү һәм бер-берсе белән аралашу өчен, аны танкистлар яки пилотлар кия.

Шлемофон – шлем с наушниками и микрофоном внутри. Его носят танкисты или пилоты, чтобы слышать команды и переговариваться между собой.

Мех комбинаты сугыш елларында
Меховой комбинат в годы войны

– Соңрак Чистай предприятиесе илебезнең иң эре «Восток» сәгать заводына әйләнә. Һәм беренче көннәрдән үк анда сәгатьләр генә түгел, хәрби ихтыяҗлар өчен кирәкле башка приборлар һәм җайланмалар да чыгарыла, – дип сүзен тәмамлады Ярдәмче. – Ә хәзер безгә икенче заводка барырга вакыт... Киттек! Юл уңаенда фронтта тагын нәрсәләр кирәк булганы турында да уйлыйк. Юнәлеш күрсәтәм: ул дошманны күзәтү өчен кулланыла.

Рома белән Зөләйха, икесе берьюлы кулларын күтәреп:

– Бинокльләр! Бинокльләр! – диде.

– Дөрес.

– Аларны да бездә ясаганнармы?!

– Әлбәттә. Бирегә Ленинград заводы эвакуацияләнә һәм безнең оптика-механика заводы белән берләштерелә. 1941 елның октябрендә Казан оптика-механика заводы 5000 данә бинокльдән торган беренче партияне фронтка озата. Алар заводның үзе белән килгән детальләрдән җыела. Аннары завод фронтка – миномёт прицеллары*, ә декабрьдә танк прицеллары бирә башлый.



Это интересно

Бу кызык

1941 елның ноябрь – декабрь айларында Казанга Мәскәүдән 1000 тоннадан артык җиһаз һәм материал төялгән 150 вагон һәм гаиләләре белән 700 гә якын хезмәткәр килә. Чистай белән тимер юл элемтәсе булмый. Казаннан бу шәһәргә кадәр юлның озынлыгы йөз километрдан арта. Кама аша кичүдә юка боз авыр җиһазлар төялгән йөк машиналарын күтәрә алмаганга, җиһазларны күчерү өчен 3000 нән артык ат олавыннан файдаланалар.

В ноябре – декабре 1941 года в Казань из Москвы прибыло 150 вагонов с более чем 1000 тонн оборудования и материалов и около 700 работников вместе с семьями. Железнодорожного сообщения с Чистополем не было, а от Казани до него – больше ста километров и переправа через Каму. Тонкий лёд не позволял пройти грузовикам с тяжёлым оборудованием, и вместо них использовали более 3000 лошадиных подвод.

Бөек Ватан сугышы елларында ТАССРга эвакуация

Эвакуация в ТАССР в годы Великой Отечественной войны

– Позже чистопольское предприятие стало крупнейшим в России часовым заводом «Восток». И с самого начала оно выпускало не только часы, но и другие приборы и устройства для военных нужд, – завершил рассказ ПОмощник. – А теперь нам пора на следующий завод... Поехали! И заодно подумайте, что ещё было необходимо на фронте. Подсказка: это нужно для наблюдения за противником.


Рома и Зулейха подняли руки одновременно:

– Бинокли! Бинокли!

– Верно.

– У нас их тоже делали?!

– Конечно. Сюда перевезли завод из Ленинграда и объединили его с нашим оптико-механическим. В октябре 1941 года Казанский оптико-механический завод уже сдал первую партию биноклей – 5000 штук; они были собраны из деталей, доставленных из города на Неве. Затем завод дал фронту миномётные прицелы*, а в декабре – танковые.



Прицел – коралны объектка төбәү җайланмасы.

Прицел – приспособление для наведения оружия на цель.

Это интересно / Бу кызык

Бөек Ватан сугышы елларында Казан оптика-механика заводы фронтка 700 меңнән артык бинокль, 30 меңнән артык орудие, миномёт һәм танк прицелы, шулай ук 1000 гә якын бомбардировка прицелы җитештереп озата.

Казанский оптико-механический завод за годы Великой Отечественной войны поставил фронту свыше 700 тысяч биноклей, более 30 тысяч орудийных, миномётных, танковых и около 1000 бомбардировочных прицелов.

Казан оптика-механика заводы турында видео кара

Посмотри видео о Казанском оптико-механическом заводе



Фронтка киткән эшчеләрне Казанда яшәүче һәм эвакуацияләнгән яшүсмерләр дә алыштыра. Алар нигездә производство цехларында ук өлкәннәрдән, тәҗрибәле эшчеләрдән эшкә өйрәнә.

– Туктагыз әле... – диде Рома уйчан гына. – Ә монда музей бармы? Аны карарга ярыймы? Исемә төште: бабайның әтисе сугыш вакытында әле малай гына булган һәм шунда эшләгән, өлкәннәрне алыштырган.

– Нигә ярамасын? Ярый...

Рома фотографияләрне бик игътибар белән карады.

– Миңа калса, менә ул.

– Яхшы, – диде Ярдәмче. – Ә йөзе чормада табылган фотосурәттәге белән берме?

– Минемчә, юк... Ләкин елы туры килә.

– Бәлки, безнең фотода аның берәр дустыдыр? – диде Зөләйха.

– Бәлки. Тик кем?

Рома көрсенеп куйды һәм уйга калды.

Это интересно
Бу кызык

Мәскәүнең 22 нче авиация заводын Казанга эвакуацияләү өчен 3000 вагон кирәк була.

Для эвакуации Московского авиационного завода №22 в Казань потребовалось 3000 вагонов.

Сугыш елларында эвакуация турында укы

Почитай об эвакуации в годы войны

Среди тех, кто заменил на заводе рабочих, ушедших на фронт, было много подростков – и жителей Казани, и эвакуированных. Они в основном учились прямо на производстве у старших, опытных товарищей.

– Постойте-ка... – задумчиво сказал Рома. – А музей тут есть? А посмотреть можно? Я вспомнил: дедушкин папа, он тогда ещё мальчишкой был, тоже во время войны там работал, взрослых заменял.

– Отчего же нельзя? Можно...

Рома старательно изучал фотографии.

– Мне кажется, вот он.

– Уже хорошо, – сказал ПОмощник. – А со снимком с чердака лицо совпадает?

– По-моему, нет... Но год тот же.

– Может, на нашем фото кто-то из его друзей? – предположила Зулейха.

– Наверное. Но кто? – Рома вздохнул и задумался.



Ярдәмче исә сүзен дәвам итте:

– Ә хәзер минем сезгә тагын бер соравым бар: техника йөрсен өчен, аңа ягулык кирәк, ә кешеләргә нәрсә кирәк?

Балалар шундук аңлап алдылар:

– Ризык!

– Дөп-дөрес. Фронтта да, тылда да. Сугыш башлангач, дошман илебезнең ашлык үстерелә, терлек үрчетелә торган территорияләренең зур өлешен яулап ала. Димәк, азык-төлек белән тәэмин итү эшендә дә төп җаваплылык тылга йөкләнә. Шул исәптән безнең республикага да. Ләкин трактор һәм машиналарның күп өлеше фронтка җибәрелә. Ә калганнарын тәртипкә китерергә кирәк була.

– Ул вакытта авылда кемнәр эшләгән соң? Ир-атлар фронтта булган бит.

– Шәһәрдәге кебек үк – хатын-кызлар, өлкән яшьтәгеләр, мәктәп укучылары. Чүп утауда, печән әзерләүдә, урып-җыюда, ашлык суктыруда. Үзләре ачлы-туклы яшәп булса да, бар нәрсәне фронтка биреп, авыл халкы фронтны азык-төлек белән тәэмин итеп тора.



Это интересно

Бу кызык

Республикабызның авыл хуҗалыгы тармагы сугышның дүрт елында дәүләткә 2 миллиард килограммнан артык икмәк, 896 миллион килограмм ит, 624 миллион килограмм бәрәңге һәм яшелчә җибәрә, 200 миллион литр сөт, дистәләгән мең пот май, терлек мае, бал, печән һәм башка продукция бирә.

Сельскохозяйственная отрасль республики за четыре года войны поставила государству более 2 миллиардов килограммов хлеба, 896 миллионов килограммов мяса, 624 миллиона килограммов картофеля и овощей, 200 миллионов литров молока, десятки тысяч пудов масла, сала, мёда, сена и другой продукции.



1941–1945 елларда Татарстанның авыл хуҗалыгы

Сельское хозяйство Татарстана в 1941–1945 годах

А ПОмощник между тем продолжил:

– Что ж, а пока у меня к вам простой вопрос: если технике нужно горючее, то что нужно людям?

Ребята сообразили сразу:

– Еда!

– Точно. И на фронте, и в тылу. А в начале войны врагом была захвачена огромная часть нашей территории, где выращивалось зерно, разводился скот. Значит, особая ответственность за обеспечение продуктами возлагалась на тыл. В том числе на нашу республику. Но многие тракторы и машины были переданы фронту. А оставшиеся надо было приводить в порядок.

– А кто тогда в деревне работал? Мужчины же были на фронте.

– Как и в городе – женщины, старики, школьники. На прополке, сенокосе, молотьбе, уборке урожая. Живя впроголодь, всё отдавая фронту, сельчане снабжали фронт.

– Ә өс-баш һәм аяк киемнәре? Алар да бик кирәк бит.

– Әлбәттә, – диде Ярдәмче. – Без инде «Спартак» аяк киеме комбинаты турында сөйләшкән идек. Башка предприятиеләр шинель*, гимнастёрка*, плащ-палаткалар, маскировка халатлары, патрон сумкалары, чаңгылар һәм тагын бик күп кирәк-яраклар җитештерә. Гомумән, безнең җиңел сәнәгать сугыш чорында көн саен бер полкны – өс-баш киемнәре, бер дивизияне аяк киемнәре белән тәэмин итә дип әйтергә була. 1941–1945 елларда республикада тегелгән кием-салым өч миллионлы армияне киендерергә җитә.



Шинель – хәрбиләр киеп йөри торган озын пальто.

Гимнастёрка – элек хәрбиләр каеш белән буып киеп йөргән, тыгыз тукымадан тегелгән озынча күлмәк.

Шинель – длинное пальто для военных.

Гимнастёрка – плотная удлинённая рубашка, которую военные в армии носили с ремнём.

– А одежда и обувь? Они ведь тоже нужны всем.

– Конечно, – отозвался ПОмощник. – Мы с вами уже говорили об обувном комбинате «Спартак». Другие предприятия делали шинели*, гимнастёрки*, плащ-палатки, маскировочные халаты, патронные сумки, лыжи и много чего ещё. Вообще, наша лёгкая промышленность в военные годы каждый день, можно сказать, одевала полк и обувала дивизию. Подсчитано, что одеждой и обувью, изготовленной в республике в 1941–1945 годах, можно было бы обеспечить трёхмиллионную армию.






Республика халкы сугышның беренче көзеннән үк сугышчыларга җылы кием-салым җыюда актив катнаша. Берничә ай эчендә фронтка 23 мең кыска тун, 54 мең пар киез итек, 59 мең телогрейка һәм шаровар*, 106 мең комплект җылы эчке кием озатыла.

Все жители республики уже с осени первого года войны участвовали в сборе тёплых вещей, необходимых бойцам. За несколько месяцев на фронт было отправлено 23 тысячи полушубков, 54 тысячи пар валенок, 59 тысяч телогреек и шаровар*, 106 тысяч комплектов тёплого белья.

Шаровар – озын киң чалбар.

Шаровары – длинные широкие штаны.

## Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында
## Художники Татарстана о Великой Победе



1985

Харис Якупов

### РӘССАМ. ФРОНТ ЮЛЛАРЫ

РСФСР һәм СССРның халык рәссамы, Бөек Ватан сугышы ветераны Харис Якупов картинасы автобиографик характерда иҗат ителгән. Ул фронтта рәссамнарның кулдан ясалган альбомнарны һәрвакыт үзләре белән йөртүләре, сугыш мизгелләрен теркәп барулары, портрет һәм жанр композицияләре эскизларын ясаулары турында сөйли. Сугышның беренче көннәреннән үк фронтта булган һәм 1946 елның гыйнварында гына хәрби хезмәтен тәмамлап кайткан Х. Якупов өчен солдатларның каһарманлыгы бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы булып хезмәт иткән.

Харис Якупов

### ХУДОЖНИК. ДОРОГИ ФРОНТОВЫЕ

Картина народного художника РСФСР и СССР, участника Великой Отечественной войны Хариса Якупова носит автобиографический характер. Она рассказывает о работе фронтовых художников, которые не расставались с самодельными альбомами, фиксируя в них моменты сражений, делая наброски портретов и жанровых композиций. Для Х. Якупова, который был на фронте с самых первых дней войны и завершил военную службу только в январе 1946 года, героизм солдат был неисчерпаемым источником вдохновения.

Харис Якупов иҗатында хәрби тематикадагы әсәрләр

Произведения военной тематики в творчестве Хариса Якупова

# Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре
# Рисунки детей к юбилею Великой Победы




Тимерлан Йосыпов рәсеме.
Арча муниципаль районы Арча 9 нчы балалар бакчасы

Рисунок Темирлана Юсупова.
Арский детский сад №9 Арского муниципального района



Валерия Чайко рәсеме.
Теләче муниципаль районы Үзәк балалар бакчасы

Рисунок Валерии Чайко.
Узякский детский сад Тюлячинского муниципального района

# Алтынчы бүлек. Бөек вал

– Ә хәзер, – диде Ярдәмче, – сугыш чорында Казан тирәсендә нәрсәләр эшләнгәнен күрербез. Кайсыгыз тарихи китаплар ярата әле?

– Мин! Мин дә! – диеште Рома белән Зөләйха.

– Алайса әйтегез: борынгы заманнарда шәһәрне һөҗүмнән нәрсәләр ярдәмендә саклаганнар?

– Диварлар корганнар. Яки биек валлар...

– Дөрес. Ә хәзер карагыз...

Сәяхәтчеләр утырган По-2 киң һәм озын траншея* өстеннән очты. Анда кулларына көрәк, лом, кәйләләр тоткан бихисап кеше эшли иде.

– Бу валны безнең шәһәрдән ерак түгел урында, сугышның иң авыр вакытында казыйлар, – дип аңлатты Ярдәмче.

– Аны саклап калыр өченме? Ләкин ул чагында вал бик озын булырга тиеш бит!

– Нәкъ шулай. Дошманны тоткарлар өчен. Трасса* өч төбәк – Татарстан, Мари һәм Чуваш республикалары буйлап барачак дип уйланыла. Казанны ул ярымбоҗра рәвешендә урап, каймалап алырга тиеш була, шуңа күрә дә аны «Казан каймасы» дип атыйлар.

Траншея – сугыш вакытында яшеренү өчен казылган озын, тар канау.

Трасса – юл, канал юнәлеше.

Казан каймасын төзүчеләр турында документаль фильм кара

Посмотри документальный фильм про строителей Казанского обвода



# Глава шестая. Великий вал

– А сейчас, – сказал ПОмощник, – мы увидим, что делалось тогда на подступах к Казани. Кто из вас любит исторические книжки?

– Я! И я! – дружно отозвались Рома и Зулейха.

– Тогда скажите: что защищало в давние времена города от нападения?

– Ну… Стены. Или высокие валы…

– Правильно. Теперь смотрите…

По-2 с путешественниками на борту плыл по воздуху вдоль широкой и длинной траншеи*. Там работало множество людей, в руках у которых были лопаты, ломы, кирки.

– Этот вал строился во время войны недалеко от нашего города, – сказал ПОмощник.

– Чтобы его защитить? Но тогда вал должен был быть очень длинным!

– Именно так. Чтобы помешать врагу пройти. Трасса* по задумке пролегала по территории трёх республик – Татарской, Марийской и Чувашской. Казань она должна была как бы «обвести» полукольцом, поэтому вал назвали «Казанский обвод».

Траншея – длинная узкая канава в земле для укрытия во время боя.

Трасса – направление дороги, канала.



– Ә бу озын валны кемнәр төзегән?


– Беренче чиратта «окоп казу»да (халык телендә шулай йөртелгән) казанлылар һәм шул як кешеләре – Апас, Кайбыч, Буа, Тәтеш һәм башка район халыклары катнашкан.

– Анда да техника җитмәгәндер инде?

– Техникага кытлык бик зур була, чөнки бөтенесе фронтка җибәрелә. Шулай да бу эш өчен дистәләгән йөк машинасы, трактор, меңләгән ат табыла. Ул елны кышы да бик салкын килә, җирне туң каплый. Күбрәк көрәк, лом, кәйлә, балта, пычкы белән эшлиләр. Коточкыч кыенлыкларга да карамастан, 1942 елның 25 гыйнварына 331 чакрым озынлыктагы каймa төзелеше тулысынча тәмамлана. Һәм ул Идел буена янаган куркыныч беткәнче сугышчан әзерлектә тотыла.

Казан каймасы турында мультфильм кара

Посмотри мультфильм о Казанском обводе



Это интересно

Бу кызык

4,5 ай эчендә Казан каймасын төзүчеләр кулдан 5 миллион кубометр чамасы (416 миллион чиләк) җир казый. 392 командир пункты, 98 яшерен ут ноктасы, 56 дзот*, 419 землянка корыла.

За 4,5 месяца строители Казанского обвода вручную выкопали около 5 миллионов кубометров (416 миллионов вёдер) земли. Было сооружено 392 командных пункта, 98 скрытых огневых точек, 56 дзотов*, 419 землянок.

Дзот – сугышчыларны ядрәдән һәм снаряд кыйпылчыкларыннан саклар өчен туфрак һәм агачтан ясалган корылма.

Дзот – сооружение из земли и дерева для защиты воюющих от пуль и осколков снарядов.

– А кто его строил?

– В первую очередь казанцы и жители тех районов, где он должен был пройти: Апастовского, Кайбицкого, Буинского, Тетюшского и других.

– Там, наверно, тоже не хватало техники?

– Очень не хватало, ведь по большей части она была на фронте. Но всё же удалось привлечь десятки грузовиков, тракторов, тысячи лошадей. Стояли сильные холода, земля промёрзла. Работали в основном тем, что всегда под рукой: лопатами, ломами, кирками, топорами, пилами. И, несмотря на все трудности, к 25 января 1942 года сооружение обвода длиной 331 километр было в целом закончено. И он поддерживался в боевой готовности до тех пор, пока сохранялась угроза Поволжью.




Казан каймасы турында видео кара

Посмотри видео о Казанском обводе



– Мондый вакытта әле тагын табиблар, хастаханәләр дә бик кирәк, – диде Зөләйха. – Медицина – шул ук саклагыч вал бит, тик авыру һәм төрле тән җәрәхәтләреннән генә.

– Бу теманы искә төшергәнең өчен рәхмәт сиңа, – диде Ярдәмче. – Бездә 1941 елның июненнән үк яралы сугышчылар, оборона заводлары эшчеләрен дәвалау өчен госпитальләрнең* тулы челтәре оештырыла.

Ярралылар Казанга сугышның унынчы көнендә үк кайтарыла башлый. Ә госпитальләр Казанда гына түгел, Әгерҗедә, Арчада, Бөгелмәдә, Буада, Яшел Үзәндә, Кукмарада, Нурлатта, Чистайда һәм башка урыннарда да оештырыла. Медицина хезмәткәрләренең фидакяр хезмәте нәтиҗәсендә, яраланган һәм авыру сугышчыларның 207 меңгә якыны, савыгып, яңадан фронтка китә, 67 меңгә якыны эш урынына кайта. Ягъни республикабыз госпитальләре сугыш кырына егерме дивизияне кире кайтаруга ирешә.

Сүз уңаеннан, Казан госпитальләренең берсендә палата табибы булып Вероника Тушнова эшли. Киләчәктә ул шагыйрә булып танылa һәм Тукай, Җәлил иҗатларын русчага тәрҗемә итә. Пациентлар аны яратып «дәфтәрле доктор» дип йөртә.

Госпиталь – яралы солдатлар һәм офицерларны дәвалый торган хастаханә.

Госпиталь – больница, где лечат раненых солдат и офицеров.

Это интересно / Бу кызык

Сугыш чорында бирeдә 41 805 урынлы 69 эвакогоспиталь ачыла. Шушы еллар эчендә республикада 334 мең яралы һәм авыру сугышчы дәвалау һәм тернәкләндерү курсы уза.

За весь военный период было создано 69 эвакогоспиталей на 41 805 коек. За эти годы в республике прошли курс лечения и восстановления 334 тысячи раненых и больных бойцов.

– А ещё в такое время очень нужны врачи и больницы, – сказала Зулейха. – Медицина – это ведь тоже защитный вал, только от болезней и ран.

– Молодец, что подсказала эту тему, – отозвался ПОмощник. – У нас после июня 1941 года была организована целая сеть госпиталей* – и для раненых бойцов, и для рабочих оборонных заводов.

Раненые в Казань прибыли уже на десятый день после начала войны. А госпитали появились тогда не только в Казани, но и в Агрызе, Арске, Бугульме, Буинске, Зеленодольске, Кукморе, Нурлате, Чистополе и других местах. Благодаря медикам около 207 тысяч из общего числа раненых и больных бойцов были возвращены в строй и около 67 тысяч – к работе. То есть госпитали нашей республики вернули фронту двадцать дивизий.

Кстати, в одном из казанских госпиталей работала палатным врачом Вероника Тушнова, будущая известная поэтесса и переводчица Тукая и Джалиля. Пациенты ласково называли её «доктор с тетрадкой».



Это интересно !? Бу кызык

Госпитальләр эше өчен донор* каны кирәк була. Казанда – унбер һәм һәр район хастаханәсендә берәр донорлык пункты ачыла. 1941 ел ахырына республикада донорлар саны 37 меңнән артып китә. Татар өлкә кан станциясе фронтка көн саен кимендә 60 литр кан җибәрә.


Для работы госпиталей требовалась доноры* для сдачи крови. Были открыты донорские пункты: одиннадцать в Казани и по одному при каждой районной больнице. К концу 1941 года число доноров в республике составляло более 37 тысяч. Татарская областная станция крови ежедневно отправляла на фронт не менее 60 литров консервированной крови.

Казан табибларының Җиңүгә керткән өлеше турында әңгәмә

Интервью о вкладе казанских врачей в Победу

**Донор** – авырып киткән яки яраланган кешеләргә үз канын бирә торган кеше.

**Донор** – человек, отдающий свою кровь для помощи раненому или больному.



– Әйдәгез, бер генә минутка булса да, Казандагы берәр госпитальгә кереп чыгыйк әле, – диде Ярдәмче. – Сугышчылар янына кемнәрдер килгән дә, ахрысы.

...Ерактарак бер палатаның тәрәзәләре ачык. Аннан гармун тавышы ишетелә. Малайларча яңгыравыклы тавыш гармунга кушыла: «С берёз, неслышен, невесом, слетает жёлтый лист...». Ул да түгел, палатадагылар гөрләтеп кул чаба һәм алып баручының: «Сезнең каршыгызда Ринат Гарипов чыгыш ясады, – дигән сүзләре ишетелә. – Ә хәзер...» Һәм бер мизгелдән икенче бала: «На позицию девушка провожала бойца...» – дип җырлап җибәрә.

– Бигрәк матур җырлыйлар, – диде Рома, Зөләйха да аны хуплап куйды. – Әгәр шул чакта яшәсәк, без дә яралылар каршында җырлар идек.

– Мондый концертлар да яралыларга һәм авыруларга дәва булган, – диде Ярдәмче. – Гомумән, Казан сугыш елларында илнең төп «даруханәсе»нә әверелә. Шәһәребез дарулар һәм төрле медицина товарлары җитештерелә торган үзәк була.

Чистай һәм Алабугага язучылар эвакуациясе
Эвакуация писателей в Чистополь и Елабугу

– Давайте навестим на минуту хотя бы один казанский госпиталь, – добавил ПОмощник. – Кажется, у бойцов как раз посетители.

...Окно дальней палаты было открыто. Оттуда доносились звуки гармони, а звонкий мальчишеский голос старательно выводил: «С берёз, неслышен, невесом, слетает жёлтый лист...» Затем раненые захлопали, и ведущая сказала: «Перед вами выступал Ринат Гарипов. А сейчас...», и через мгновение запел уже другой детский голос: «На позицию девушка провожала бойца...»

– Здорово поют, – сказал Рома, а Зулейха согласно кивнула. – И мы бы для раненых спели, если бы тогда жили...

– Такие концерты тоже были помощью больным и раненым, – сказал ПОмощник. – А вообще, Казань в военные годы стала главной «аптекой» страны. Центром, где делались лекарства и различные медицинские материалы.




Это интересно
Бу кызык


Чистайга һәм республиканың башка төбәкләренә А. Ахматова, К. Чуковский, Б. Пастернак, А. Фадеев, С. Маршак, А. Твардовский һәм башка бик күп танылган язучылар эвакуацияләнә. Сугыш елларында күп кенә яңа әсәрләр иҗат ителә, шул исәптән Михаил Исаковскийның «В лесу прифронтовом» шигыре дә. Ул тиздән халыкның яраткан җырына әверелә.

В Чистополь и другие районы республики были эвакуированы многие известные писатели: А. Ахматова, К. Чуковский, Б. Пастернак, А. Фадеев, С. Маршак, А. Твардовский и другие. В годы войны было создано немало новых произведений, в том числе стихотворение Михаила Исаковского «В лесу прифронтовом», вскоре ставшее любимой народом песней.

«В лесу прифронтовом» җырын тыңла
Послушай песню «В лесу прифронтовом»

– Мин әнидән җәрәхәтләрне тегү өчен кулланыла торган махсус җеп турында ишеткән идем, – диде Зөләйха. – Ул куркынычсыз һәм бик нык.

– Кетгут ул, – диде Ярдәмче. – Казан кетгут заводы илдә шундый җепләр ясый торган бердәнбер завод санала. Сугыш вакытында биредә җитештерүне биш тапкырга арттыралар. Ә тагын Казан медицинасы Бөек Ватан сугышы тарихына яңа ысуллар һәм дәвалау чаралары уйлап табуы белән дә кереп кала. Мәсәлән, А. В. Вишневский авыртуны новокаин белән басу ысулын уйлап таба. Яраларны Вишневский мазе белән бәйләү дә бик уңышлы кулланыла; безгә бу ысул хәзер дә бик таныш.



Казан кетгуты турында укы
Почитай о казанском кетгуте

А. Вишневский турында видео кара
Посмотри видео об А. Вишневском

– Я от мамы слышала про специальную нитку, которой зашивают раны, – сказала Зулейха. – Она безопасная и очень прочная.

– Это кетгут, – отозвался ПОмощник. – Казанский кетгутный завод, единственный в стране, давно делает такие нити. За время войны их выпуск увеличился здесь больше чем в пять раз. А ещё казанская медицина вошла в историю Великой Отечественной войны новыми способами и средствами лечения – например, разработанным А. В. Вишневским методом обезболивания новокаином. А при ранах успешно применялись повязки с мазью Вишневского; с ней и сейчас знакомы многие, кому случалось пораниться.

Казан химфармзаводының Җиңүгә керткән өлеше

Вклад Казанского химфармзавода в Победу



Это интересно / Бу кызык

1941 елның июлендә үк Казан химфармзаводында (хәзер ул – «Татхимфармпрепаратлар») махсус химия цехы җиһазландырыла, анда көчле авыруларны дәвалау һәм канны консервацияләү матдәләре ясала. 1944 елда җирле чималдан ике миллион сумлык даруханә продукциясе җитештерелә.

Уже в июле 1941 года на Казанском химфармзаводе (ныне это «Татхимфармпрепараты») был оборудован специальный химический цех, где выпускались средства для лечения тяжёлых заболеваний и для консервации крови. В 1944 году из местного сырья было изготовлено аптечной продукции на два миллиона рублей.

## Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында

## Художники Татарстана о Великой Победе



Әсхәт Сәфәргалин 1965 Асхат Сафаргалин

### ФРОНТ ЮЛЛАРЫНДА. ШӘФКАТЬ ТУТАШЫ

Рәссам Әсхәт Сәфәргалин үз картиналарында иң мөһим нәрсә – тормыш сөюне күрсәтә алган. «Фронт юлларында. Шәфкать туташы» картинасында ике яралы солдат яткан ат арбасы сурәтләнгән.

Нәфис гәүдәле шәфкать туташы аларны госпитальгә озата бара. Аның кулындагы автомат безгә якында сугыш баруы, арбаның куркыныч урын аша узуы турында сөйли. Ләкин якты кояш һәм шәфкать туташы кулындагы язгы чәчәкләр бәйләме күңелне тынычландыра, барысы да яхшы булачак дигән өмет уята. Рәссам картинада сурәтләнгән кешеләрнең көчле рухын һәм якты киләчәккә ныклы ышанычын күрсәтергә омтылган.

### НА ФРОНТОВЫХ ДОРОГАХ. МЕДСЕСТРА

Художник Асхат Сафаргалин в своих картинах сумел показать самое главное – любовь к жизни. Картина «На фронтовых дорогах. Медсестра» демонстрирует конную повозку, в которой лежат двое раненых солдат.

Хрупкая, нежная медсестра сопровождает их в госпиталь. Автомат в её руках говорит нам, что война ещё идёт и что повозка движется по опасному участку. Однако светящее солнце и букет весенних цветов в руке медсестры успокаивают нас, дают уверенность в том, что всё будет хорошо. Художник старался подчеркнуть, что изображённые на картине люди имеют силу и стойкую веру в светлое будущее.

Татарстанлы шәфкать туташлары һәм санитаркалар турында укы

Почитай о медсёстрах и санитарках из Татарстана

## Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре
## Рисунки детей к юбилею Великой Победы




Аделина Мөхәммәтгалиева рәсеме.
Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсенең гомуми үсеш төрендәге 5 нче санлы балалар бакчасы

Рисунок Аделины Мухаметгалиевой.
Детский сад №5 общеразвивающего вида посёлка городского типа Уруссу Ютазинского муниципального района



Алмир Вәлиев рәсеме.
Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авылы «Кыңгырау» балалар бакчасы

Рисунок Альмира Валиева.
Детский сад «Кынгырау» села Большие Кляри Большекляринского сельского поселения
Камско-Устьинского муниципального района





# Җиденче бүлек. «Совет информбюросыннан...»

– Кызык, ә сугыш вакытында газеталар чыкканмы икән? Ярдәмче гүя шушы сорауны көткән иде.

– Ничек инде чыкмасын! – диде ул. – Алар фронт белән тылны, алгы сызыктагы сугышчыларны туганнары һәм якташлары белән бәйләп торган, кешеләрдә җиңүгә ышанычны ныгыткан. Газета битләре дә, радио да фронттагы барлык яңалыкларны яктыртып барган. Ул чорда сугыштагы вакыйгалар турында көндезге һәм кичке хәбәрләр басылган «Совет информбюросыннан» рубрикасын бөтен кеше белгән. Сүз уңаеннан, анда исемнәр дә, атамалар да күрсәтелмәгән. Ничек уйлыйсыз, ни өчен икән?

– Бәлки, дошман бу мәгълүматлардан файдалана алмасын өчендер? – диде Рома. – Газетаның дошман кулына эләгү ихтималы да булган бит...

– Минемчә, син хаклы. Бары тик 1944 елда гына хәбәрләрдә чын фамилияләр һәм атамалар чагылыш таба башлый.




# Глава седьмая. «От Советского информбюро...»

– Интересно, а газеты во время войны выходили?
ПОмощник будто ждал этого вопроса.

– А как же! – сказал он. – Они связывали фронт и тыл, бойцов нашей армии с родными и земляками, поддерживали в людях уверенность в победе. На их страницах, как и в радиотрансляциях, сразу отражалось то, что происходило на фронте. Рубрику «От Советского информбюро», где печатались дневные и вечерние сообщения о событиях на фронте, знали тогда все. Кстати, названия и имена там поначалу были скрыты. Как вы считаете, почему?


– Может быть, чтобы врагам не удалось воспользоваться этими сведениями? – предположил Рома. – Ведь газета могла попасть в руки неприятеля...

– Я думаю, ты прав. Только в 1944 году в сообщениях появились реальные фамилии и названия.

# ТАТАРСТАН – ФРОНТКА

Республиканың «Кызыл Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Советская Татария», «Комсомолец Татарии» һ.б. газеталарында шәһәрләрдә, завод-фабрикаларда, колхоз кырларындагы эшнең торышы, фронтка азык-төлек һәм техника озату, башка төр ярдәм турында мәгълүмат күп була. Шулай ук балаларның фронтка булышуы: зурракларының станок артында һәм колхоз кырларында өлкәннәрне алыштырулары, кечерәкләренең тимер-томыр җыюлары яки сабыйлары булган гаиләләргә азык-төлек илтүләре турында да язылган. Шулай ук балаларның госпитальләрдә яралылар каршында чыгыш ясаулары да чагылдырылган.





Это интересно

Бу кызык

1942 елның июлендә республика пионерлары Мәктәп укучылары һәм пионерлар арасында авыл хуҗалыгы эшләре буенча бөтенсоюз ярышында катнаша. «Пионерская правда» газетасы, мәсәлән, июль аенда Казандагы 86 нчы мәктәпнең 28 кешелек отряды 96 гектардагы төрле культураларның чүбен утады һәм 125,5 тонна печән җыеп алды, дип билгеләп үтә.

В июле 1942 года пионеры республики приняли участие во Всесоюзном соревновании среди школьников и пионеров по сельскохозяйственным работам. Газета «Пионерская правда» отмечала, например, что за июль отряд казанской школы №86 в составе 28 человек прополол 96 гектаров различных культур и убрал 125,5 тонны сена.


ДА ЗДРАВСТВУЕТ НАША ПОБЕДА!
Красная Татария


Комсомолец Татарии
В дозоре
От Советского Информбюро


Пионерская правда
Собирайте шиповник!
От Советского Информбюро
Враг поплатится

В газетах республики – «Красной Татарии», «Комсомольце Татарии» и других – было много информации о работе на полях в колхозах, на заводах, в городах, о поставках продуктов и техники, о помощи фронту. Писали о том, как помогают фронту дети: старшие, заменяя мужчин у станков и на колхозных полях, а те, кто помладше, собирал металлолом, доставлял на дом продукты семьям с малышами или выступал для раненых в госпиталях.

Это интересно
Бу кызык

Сугышның беренче елыннан ук илебез матбугаты танылган галим һәм язучыларның фашистларга каршы сугышның мәдәният һәм бөтен кешелек язмышы өчен көрәш булуын чагылдырган мәкалә-мөрәҗәгатьләрен бастырып бара. Газеталарда совет гаскәрләренең уңышы, сугышчыларның батырлыклары, аларга мактаулы исем һәм бүләкләр бирелүе, тылдагыларның фидакяр хезмәте турында хәбәрләр басыла. Фронт матбугаты битләрендә, шул исәптән якташ язучыларыбыз Фатих Кәрим, Гадел Кутуй һәм башка бик күпләр сугышкан урыннардагы басмаларда патриотик шигырьләр дә урын ала.

Пресса страны с первого года войны публиковала статьи-обращения известных учёных и писателей, в которых говорилось о том, что война с фашистами – это битва за судьбу культуры и всего человечества. Газеты сообщали об успехах советских войск, о подвигах, присвоении званий и наград, об ударном труде в тылу. Публиковались в них и патриотические стихи. Как и во фронтовых печатных изданиях, выпускавшихся в том числе там, где воевали наши земляки-писатели – Фатих Карим, Адель Кутуй и многие другие.

Сугыш елларында татар матбугаты турында видео кара

Посмотри видео о татарских СМИ в годы войны

Романың кесәсендәге телефон тагын шылтырады.

– Тыңлыйм, Вова дәдәй...

– Сәлам! Мин тагын бер нәрсәне укый алдым! – диде фотограф. – Җырның бер юлын! Бик иске! «С берёз, неслышен, невесом...»

– Слетает жёлтый лист?

– Син нәрсә, әллә беләсең инде?

– Ишеттем! Күптән түгел генә! – диде Рома, шатланып. – Рәхмәт! Туктагыз әле, туктагыз! Госпитальдә сугышчылар каршында җырлаган малайның исеме ничек?

– Ринат Галиев... Юк, Галимов... – Зөләйха да тиз генә исенә төшерә алмады.

– Сез серне чишүгә тагын да якынайдыгыз, ахрысы, – диде Ярдәмче. – Ләкин безгә кузгалырга вакыт...

Һәм дуслар гадәттә күргәзмә залы дип атала торган бер зур залга килеп керделәр.







Сапёр – миналарны зарарсызландыручы һәм аларны куючы, шулай ук сазлык һәм елгалар аша кичүләрне тәэмин итүче солдат.

Сапёр – солдат, который обезвреживает мины или, наоборот, устанавливает их, чтобы помешать врагу пройти. Сапёр также обеспечивает переправы через болота и реки.

В кармане у Ромы снова зазвонил сотовый телефон.

– Да, дядя Вова...

– Привет! Ещё кое-что прочёл! – сказал фотограф. – Строчку из песни! Очень старой! «С берёз, неслышен, невесом...»

– Слетает жёлтый лист?

– Ты что, её знаешь?

– Слышал! Совсем недавно! – радостно сказал Рома. – Спасибо! Постойте, постойте! Как звали мальчика, который в госпитале для бойцов пел?

– Ринат Галеев... Нет, Галимов... – у Зулейхи тоже не получалось с ходу вспомнить.

– Похоже, вы уже близки к разгадке тайны, – сказал ПОмощник. – Но нам снова пора...

И ребята оказались в большом зале – из тех, что обычно называются выставочными.





Харис Якуповның фронтта ясаган рәсемнәре

Фронтовые зарисовки Хариса Якупова

Это интересно / Бу кызык

Бөек Ватан сугышында йөзгә якын Казан рәссамы катнаша. Алар пехотачылар һәм артиллеристлар, очучылар һәм танкистлар, моряклар, элемтәчеләр, сапёрлар*, механиклар, санинструкторлар, топографлар булып хезмәт итә. Күбесе фронтта да карандаш-альбомнарыннан аерылмый, сугыш кырыннан үзләре белән бик күп эскизлар, зарисовкалар һәм полкташларының портретларын алып кайта.

В Великой Отечественной войне участвовало около ста казанских художников. Они были пехотинцами и артиллеристами, лётчиками и танкистами, моряками, связистами, сапёрами*, механиками, санинструкторами, топографами. Многие и на фронте не расставались с карандашом и альбомом, и те, кто вернулся, привезли с собой множество набросков, зарисовок и портретов однополчан.

Татарстан рәссамнары сугышта һәм сугыш турында

Художники Татарстана на войне и о войне

– Уртак җиңүгә сәнгать кешеләре дә үз өлешен керткән: көйләр иҗат иткәннәр яки башкарганнар, спектакльләр куйганнар, китаплар язганнар, кино төшергәннәр, рәсем ясаганнар, – дип дәвам итте Ярдәмче. – Үзегез күреп торасыз: болар сугыш еллары картиналары. Рәссамнар тылда үз сәнгатьләре аша да, фронтта корал тотып та сугышканнар.

Казан рәсем осталары Байназар Әлменов, Николай Сокольский, Эрнст Гельмс һәм башкаларның рәсемнәре буенча «Сатира тәрәзәсе» өчен плакатлар ясалган. Алар кулдан эшләнгән һәм, кеше күп булган урыннарга урнаштырылып, эчке һәм халыкара тормышка кагылышлы вакыйгаларны чагылдырган.

Ә Бөгелмәдә туып-үскән, Татар сәнгать техникумын тәмамлаган, аннары Симферопольдәге Кырым драма театрының баш рәссамы булып эшләгән Николай Барышев театр рәссамы буларак кына түгел, ә яшерен антифашистлар төркеме җитәкчесе буларак та билгеле.



Это интересно

Бу кызык

Ул чорда күтәрелгән темалар картиналарның исемнәрендә үк чагылыш тапкан. Мәсәлән, Г. А. Рахманкулованың «Фронтовиклар әнисе Саракҗиеваның портреты», К. Е. Максимовның «Торф әзерләүдә», «Олыларга ярдәм», «Колхозга эвакуацияләнгәннәр» картиналары. Рәссам Бакый Урманченың да ул чор әсәрләре арасында «Госпитальдә» һәм «Снайпер Афанасьев портреты» кебек картиналары бар. Хәзерге вакытта Казанда бу рәссам исемен йөрткән музей эшли.

Названия картин того времени говорят сами за себя. Например, «Портрет Саразеевой, матери фронтовиков» Г. А. Рахманкуловой, «Заготовка торфа», «Помогают взрослым», «Эвакуированные в колхозе» К. Е. Максимова… У художника Баки Урманче, чьё имя носит сейчас один из казанских музеев, среди картин той поры есть, например, полотна «В госпитале» и «Портрет снайпера Афанасьева».

Сугыш елларында рәсем сәнгате

Изобразительное искусство в годы войны













– Свой вклад в общую победу внесли и люди искусства, – продолжил ПОмощник, – те, кто сочинял или исполнял музыку, играл или ставил спектакли в театрах, писал книги, снимал кино... Или рисовал. Сами смотрите: это картины военных лет. Художники тоже воевали – и на фронте, и с помощью своего искусства.

По рисункам казанских мастеров Байназара Альменова, Николая Сокольского, Эрнста Гельмса и других создавались плакаты для «Окон сатиры». Они делались вручную, устанавливались в людных местах и отражали события внутренней и международной жизни.

А уроженец Бугульмы Николай Барышев, выпускник Татарского техникума искусств, а затем главный художник Крымского драматического театра в Симферополе, известен не только как театральный художник, но и как руководитель подпольной антифашистской группы.

Это интересно – Бу кызык



Н. А. Барышев һәм аның көрәштәшләре фашистларны Симферопольдән куып чыгарырга өч көн кала һәлак була. Аларның каһарманлыгы турында СССР Дәүләт премиясенә лаек булган «Они были актёрами» спектакле куела, ә соңрак шул ук исемдәге нәфис фильм төшерелә.

Н. А. Барышев и его соратники погибли за три дня до изгнания фашистов из Симферополя. Об их подвиге был поставлен спектакль «Они были актёрами», удостоенный Государственной премии СССР, а позже снят одноимённый художественный фильм.

Татарстан рәссамнарының «Сатира тәрәзәсе»

«Окна сатиры» татарстанских художников

# Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында

# Художники Татарстана о Великой Победе



1989

Александр Родионов

## САПЁРЛАР

Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына багышланган тематик картиналар ТАССРның халык рәссамы Александр Родионов иҗатында төп урынны алып тора. А. Родионов фронтта була, һәм сугыш еллары вакыйгалары аның хәтерендә гомеренең ахырынача уелып кала. Нәкъ шул елларда ул рәсем ясый башлый, зарисовкалар төшереп, үзенә күрә фронт көндәлеге алып бара.

«Сапёрлар» картинасы рәссамның күңел хатирәләре нигезендә ясалган. Ул Бөек Җиңүгә юл ачкан сугышчыларның батырлыгына дан җырлый.

Александр Родионов

## САПЁРЫ

Тематические картины, посвящённые событиям Великой Отечественной войны, стали в творчестве народного художника ТАССР Александра Родионова самыми важными. А. Родионов был на фронте, и события военных лет до конца жизни остались в его памяти. Именно в те годы он начал рисовать, делал зарисовки – вёл своеобразный фронтовой дневник.

Картина «Сапёры» написана на основе воспоминаний художника. Она воспевает подвиг воинов, которые прокладывали путь к Великой Победе.

Сапёр татарлар турында укы

Почитай о сапёрах-татарах

# Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре
# Рисунки детей к юбилею Великой Победы




Рамзан Шәмсетдинов рәсеме.
Яшел Үзән муниципаль районының 10 нчы «Йолдызлык» балалар бакчасы

Рисунок Рамзана Шамсутдинова.
Детский сад №10 «Созвездие» Зеленодольского муниципального района




Демид Латыйфуллин рәсеме.
Бөгелмә муниципаль районы катнаш төрдәге 12 нче «Буратино» балалар бакчасы

Рисунок Демида Латифуллина.
Детский сад комбинированного вида №12 «Буратино» Бугульминского муниципального района

# Сигезенче бүлек. Хәтер – ул галәм

– Без әлеге күргәзмә залына очраклы рәвештә генә эләкмәдек, – диде Ярдәмче. – Сәяхәтебез ахырына якынлаша. Һәм ул моңа охшаш залда тәмамланачак, ләкин без аның бик аз өлешен генә карый алачакбыз.

– Ә ни өчен бик аз өлешен?

– Чөнки ул бик зур – иксез-чиксез дип әйтергә мөмкин. Һәм чиксез дәрәҗәдә кызык та. Әйдәгез, үзегез карагыз...



# Глава восьмая. Память – это космос

– Мы с вами не случайно оказались в выставочном зале, – сказал ПОмощник. – Путешествие наше заканчивается. А завершится оно в похожем зале, но мы сможем лишь немножко осмотреть его.

– Почему немножко?

– Потому что он огромный, можно сказать, бесконечный. И бесконечно интересный. Смотрите сами...



Бу юлы күчү гадәттәгегә караганда озаграк дәвам итте. Һәм балалар картиналар галәмдәге йолдызлар кебек чиксез күп булган, стеналарсыз залга килеп керделәр. Һәрхәлдә, Зөләйха белән Рома, картиналарны күреп, әнә шулай космос турында уйлап куйдылар.

– Бу тулы бер галәм, – диде Ярдәмче, аларның нәрсә уйлаганнарын ишеткәндәй. – Аның ничек аталганын тиздән сез үзегез миңа әйтерсез. Әйдәгез, башта якынрак килик. Ә аннары картина астындагы язуны укырбыз. Сез нәрсә күрәсез?


– Бу вокзал, – диде Зөләйха. – Яңа гына хәрби хезмәткә алынганнар утырган поезд менә-менә кузгалырга тора. Мөгаен, фронткадыр – әнә вагон янында бер хатын кулъяулыгы белән күз яшьләрен сөртә...



На этот раз перемещение длилось дольше, чем обычно. И ребята очутились в действительно бесконечном зале, где не было стен, зато картин – как звёзд в космосе. По крайней мере, так Зулейха и Рома подумали.

– Это целое космическое пространство, – словно услышав их мысли, сказал ПОмощник. – Как оно называется, вы сами скоро мне скажете. Давайте сначала подойдём ближе. А потом прочтём описание к картине на табличке внизу. Что вы видите?

– Это вокзал, – сказала Зулейха. – И состав с новобранцами, который вот-вот отправится. Наверно, на фронт – вот женщина рядом с вагоном вытирает слёзы платочком...




Это интересно / Бу кызык

Республика сугыш елларында хәрәкәттәге армия өчен резерв үзәгенә әверелә. Биредә 180 меңнән артык кеше гомуми мәҗбүри хәрби уку системасында әзерлек үтә, ике авиация һәм җиде укчы дивизиясе, ун аерым полк һәм батальон, илнең Хәрби-һава көчләре өчен йөзләгән хәрби экипаж формалаштырыла.

Республика в годы войны стала кузницей резервов действующей армии. Здесь прошли подготовку в системе всеобщего военного обучения свыше 180 тысяч человек, были сформированы две авиационные и семь стрелковых дивизий, десять отдельных полков и батальонов, сотни боевых экипажей Военно-воздушных сил страны.

# ТАТАРСТАН – ФРОНТКА



– Ә бу картинада?

– Монысы инде фронтта, – диде Рома. – Сугышчы фашист танкына граната ыргыта.

– Әйе, тик бу граната түгел, ә яндыргыч катнашма тутырылган шешә, аның бер төрен бездә, Казанда, уйлап тапканнар.

– А на этой?

– А это уже на фронте, – сказал Рома. – Боец бросает гранату в фашистский танк.

– Да, только это не граната, а бутылка с зажигательной смесью, один из видов которой придумали у нас в Казани.

Это интересно

!?

Бу кызык

Фашист танкларына каршы куәтле көрәш чарасына әверелгән ягулык катнашмасы составын атаклы химиклар А. Е. Арбузов һәм Б. А. Арбузов уйлап таба. Дарыларның яңа составын, танк һәм самолётлар өчен яңа оптик приборлар, корабларны мина һәм торпедалардан саклау ысулларын эшләү, тәкъдим итү – республика галимнәре тарафыннан хәл ителгән фәнни оборона проблемаларының бер өлеше генә. Кагыйдә буларак, аларның фәнни эзләнү нәтиҗәләре турыдан-туры предприятиеләргә кертелә, ә аннары инде фронтка озатыла.

Состав горючей смеси, ставшей мощным средством борьбы с фашистскими танками, был разработан выдающимися химиками А. Е. Арбузовым и Б. А. Арбузовым. Разработка состава порохов, новых оптических приборов для танков и самолётов, способов защиты кораблей от мин и торпед – лишь часть научных оборонных проблем, над которыми работали учёные республики. Как правило, результаты их научного поиска сразу поступали на предприятия, а затем уже на фронт.

Сугыш елларында Казан галимнәренең ачышлары турында видео кара

Посмотри видео об открытиях казанских учёных в годы войны

– Ә фотодагы дәрестә кызлар гына...
– Эш монда аларның нәрсә өйрәнүләренә бәйле, – диде Ярдәмче.
– Мөгаен, шәфкать туташларыдыр! Яисә санитаркалар! – диде Зөләйха.
– Әйе. Җәрәхәтләрне бәйләргә, укол ясарга – кыскасы, яралыларга ярдәм күрсәтергә өйрәнәләр.

– А на фотографии, сделанной во время занятия, только девушки...
– Вопрос в том, чему именно они учатся, – сказал ПОмощник.
– Наверно, это медицинские сёстры! Или санитарки! – догадалась Зулейха.
– Да. Учатся перевязывать раны, делать уколы – в общем, помогать раненым...





«Санитар оборонага әзер!» түгәрәге җитәкчесе М. И. Лапина бәйләвеч салырга өйрәтә. 1941 ел

Руководитель кружка «Готов к санитарной обороне!» М. И. Лапина показывает, как делать повязки. 1941 год




Республикада фронт өчен Кызыл Хач һәм Кызыл Ярымай җәмгыяте тарафыннан җиде меңгә якын шәфкать туташы һәм сандружиначы әзерләнә. «Санитар оборонага әзер!» һәм «Санитар оборонага әзер бул!» программалары буенча да массакүләм әзерлек оештырыла.

В республике Обществом Красного Креста и Красного Полумесяца было подготовлено почти семь тысяч медсестёр и сандружинниц. Также было организовано массовое обучение по программам «Готов к санитарной обороне!» и «Будь готов к санитарной обороне!».

Казан дәүләт медицина институты сугыш елларында

Казанский государственный медицинский институт в годы войны




– Ә монда һәйкәл... – диде Зөләйха. – Тик ул кешегә түгел, самолётка куелган. Ә аның тышкы ягына «Бөгелмә колхозчысы» дип язылган.

– Бу Пе-8 бомбардировщигы, – дип ачыклык кертте Ярдәмче. – Ул 1943 елның башында Бөгелмә районы халкы җыйган акчага төзелә. Ә ел ахырында самолёт инде сугышларда катнаша.

– Ә бу, мөгаен, сугыш ветераны портретыдыр. Күкрәгендәге орден-медальләре генә дә күпме...

– Әйе, фронтта сугышкан яисә сугыш елларында тылда эшләгән барлык ветераннарыбыз да шундый портретка лаек.

– А здесь памятник... – сказала Зулейха. – Только он не человеку, а самолёту. А на боку у него написано «Бугульминский колхозник».

– Такой самолёт, – сказал ПОмощник, – бомбардировщик Пе-8, был построен в начале 1943 года на деньги, собранные жителями Бугульминского района. А в конце года он уже воевал.

– А это, наверное, портрет ветерана войны. Сколько у него наград...

– Да, такого портрета заслуживают все наши ветераны, сражавшиеся на фронте или трудившиеся в тылу в годы войны.



Советлар Союзы Геройларына бирелә торган **«Алтын Йолдыз» медале**

**Медаль «Золотая Звезда»**, которую вручали Героям Советского Союза



Социалистик Хезмәт Геройларына бирелә торган **«Урак белән Чүкеч» медале**

**Медаль «Серп и Молот»**, которую вручали Героям Социалистического Труда




I, II һәм III дәрәҗә **Дан ордены**

**Орден Славы** I, II и III степени



Фән һәм сәнгать эшлеклеләренә бирелә торган **Сталин премиясе лауреаты медале**

**Медаль лауреата Сталинской премии**, которую вручали деятелям науки и искусства

Это интересно

Бу кызык

Республика халкының батырлыгы югары бүләкләр белән билгеләнә: 200 меңнән артык кеше орден һәм медальләр ала, 50 гә якын кеше Дан орденының тулы кавалеры була, ә тагын 351 кешегә Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Җиңү яулау өчен тылда көч куйган 4200 кеше, сугыш елларындагы героик хезмәтләре өчен, бүләккә лаек була.

Героизм жителей республики был отмечен высокими наградами: свыше 200 тысяч её уроженцев получили ордена и медали, почти 50 стали полными кавалерами ордена Славы, а ещё 351 человек удостоен звания Героя Советского Союза. Отмечены были и те, кто ковал Победу в тылу: 4200 жителей были награждены за героический труд в годы войны.

Дан орденының тулы кавалеры З. Арсланов турында видео кара

Посмотри видео о полном кавалере ордена Славы З. Арсланове

– Ә монда балалар госпитальдә яралылар каршында чыгыш ясый, – диде Рома.

– А здесь дети выступают в госпитале для раненых, – сказал Рома.



Это интересно

Бу кызык

Сугышның беренче елында гына да Татарстан госпитальләрендә 2756 концерт, 628 үзешчән сәнгать кичәсе, 559 әдәби кичә оештырыла, 83 спектакль куела.

Только за первый год войны в госпиталях Татарии было проведено 2756 концертов, 628 вечеров художественной самодеятельности, 559 литературных вечеров и показано 83 спектакля.

ТАССРда эвакуация госпитальләре

Эвакуационные госпитали в ТАССР

– Туктагыз, – диде Зөләйха. – Язуларда исемнәр дә бар... Гарипов Ринат...

– Гарипов! – дип кычкырып җибәрде Рома. – Нәкъ шулай! Ринат Гарипов иде аның исеме. Йөзе дә шул. Димәк, ул минем бабама теге фотоны бүләк иткән. Без аны таптык!

Балалар шатлыктан, бер урында сикерешә-сикерешә, бер-берсенең җилкәләрен каккаладылар...

– Булдырдыгыз! – диде Ярдәмче. – Сезнең эзләнүләрегез тәмамланды дияргә була. – Һәм өстәп куйды: – Күп еллар узса да, без Бөек Ватан сугышы кырларыннан әйләнеп кайтмаганнарны онытмаячакбыз. Хәзер безнең күптомлы «Хәтер китабы» бар, өстәвенә аның электрон формасы да эшләнгән. Хәзер кайда икәнебезне аңлагансыздыр инде? Бу киңлек, бу галәм нәрсә дип атала?




– Постойте, – сказала Зулейха. – На табличке и имена есть... Гарипов Ринат...

– Гарипов! – закричал Рома. – Точно! Его звали Ринат Гарипов. И лицо то же. Значит, это он моему прадедушке то фото подарил. Мы его нашли!

И ребята принялись подскакивать на месте и хлопать друг друга по плечу...

– Молодцы! – сказал ПОмощник. – Похоже, ваш поиск почти окончен. – И добавил: – А тех, кто не вернулся с фронтов Великой Отечественной, мы будем помнить, сколько бы лет ни прошло. И у нас теперь есть многотомная «Книга Памяти», причём и в электронном виде. И вы, наверное, уже поняли, где мы с вами сейчас находимся? Это пространство, этот космос называется...

– Хәтер! – дип җавап бирде Рома белән Зөләйха бертавыштан.

– Мин сезнең акыллы да, зирәк тә булганыгызны беләидем. Монда музейлар, китаплар, фильмнар, картиналар, спектакльләр, җырлар ярдәмендә эләгергә мөмкин; болар барысы да, фантастик китапларда әйтелгәнчә, – «порталлар», ягъни теләсә кайсы урынга һәм вакытка керү-үтү юллары. Яки минем белән үтеп була. Ә галәмне тулысынча берәү дә карап бетерә алмаячак, чөнки аның, ягъни безнең уртак Хәтеребезнең иге дә, чиге дә юк. Һәм мин әле тагын дуслашуыбызга да бик канәгать.

– Без дә! Без дә бик шат! Рәхмәт!

– Инде хушлашырга да вакыт.

Һәм Ярдәмче, кайчандыр пәйда булган кебек, әкрен генә һавада эреп юкка чыкты. Бөтенләй күздән югалганчы, Рома белән Зөләйха аның: «Әгәр кирәк булсам, ничек табарга кирәклеген беләсез!» дигән сүзләрен ишеттеләр.



– Память! – хором сказали Рома и Зулейха.

– Я знал, что вы сообразительные. Попасть сюда можно с помощью музеев, книг, фильмов, картин, спектаклей, песен; ведь всё это, как говорят в фантастических книгах, – «порталы», то есть входы в любые места и времена. Ну или со мной. А пройти весь космос ни у кого не получится, потому что он, то есть общая наша Память, не имеет ни конца, ни края. И ещё я очень доволен, что мы стали друзьями.

– И мы! И мы рады! Спасибо!

– Ну что ж, тогда пора прощаться.

И ПОмощник медленно растаял в воздухе – так же, как когда-то появился. Но прежде чем он исчез совсем, Рома и Зулейха услышали: «А если что – вы знаете, как меня найти!»



...Ринатны, ягъни Ринат Наилевичны дуслар бик тиз тапты. Трубкадагы тавыш яшь булмаса да, шактый көр тоелды аларга.

Фатир ишеге ачылуга, бусагадан ук балалар бертавыштан: «Исәнмесез, бу без!» – дип, аңа туп-туры иске фоторәсемне суздылар.

Кунакларны тәм-томнар куелган чәй өстәле янына чакыргач, хуҗа да янәшәдәге урындыкка килеп утырды һәм фотоны бик озаклап карарга кереште. Шулкадәр җентекләп караганга, Рома белән Зөләйха, әллә дөрес килмәдекме икән дип, шикләнә үк башладылар. Бераздан Ринат ага балаларга күтәрелеп карады:

– Бу фотоны күптән күргәнем юк иде... Без, Рома, синең бабаңның әтисе белән госпитальләрдә бик еш чыгыш ясадык. Һәм һәрвакыт «В лесу прифронтовом» җырын җырлый идек. Сугышчылар да аны бик яраталар иде. Аннан соң Вася белән безнең юллар бик озакка аерылды, шуңа күрә мин, саубуллашканда, аңа бу фотоны бүләк иттем.

Ул дулкынланудан бүлмә буйлап йөренә башлады.

– Без бит ул чакта сезнең кебек кенә идек. Әмма без бар көчебезгә тырыштык. Безнең буын, сугыш чоры балалары да, – шулай ук Җиңүгә китерүчеләр. Бу еллар бик авыр булса да, героик еллар иде. Әлеге чор халкыбызны тагын да көчлерәк итте: сынаулардагы ныклыкның рухны чыныктыруы билгеле бит...



...Рината, то есть Рината Наилевича, ребята отыскали на удивление быстро. Голос в трубке им ответил – немолодой, но бодрый.

Когда дверь его квартиры открылась, они прямо с порога, одновременно со словами «Здравствуйте, это мы!», протянули ему старую фотографию.

Усадив гостей за стол с чаем и конфетами, хозяин опустился на стул рядом и долго рассматривал снимок – так долго, что Рома и Зулейха уже начали сомневаться, точно ли по адресу они попали. Но потом Ринат Наилевич поднял глаза от фотографии:

– Давненько я не видел этого снимка... Мы с прадедушкой твоим, Рома, мальчишками часто в госпиталях выступали, и каждый раз «В лесу прифронтовом» пели. Любили песню бойцы. А с Васей у нас потом дороги надолго разошлись, потому я и подарил ему на прощание это фото.

Он взволнованно заходил по комнате.

– Мы же тогда не старше вас были. Но мы старались изо всех сил, и моё поколение, дети военного времени, – тоже внесли свой вклад в Победу. Это были очень трудные, но героические годы. Они наш народ сделали ещё сильнее: известно ведь, что стойкость в испытаниях душу укрепляет...



– 9 Май – минем өчен, безнең барыбыз өчен иң зур бәйрәм шул ул! Бигрәк тә хәзер. 2025 елда **Бөек Җиңүнең 80 еллык юбилее** бит! Хәтер өчен рәхмәт сезгә, балалар. Хәтергә тугрылык – зур эш. Аның ышанычлы кулларда булуына мин бик шат!

Ринат ага бераз дәшми торды. Дусларның мактаудан уңайсызланып калуларын күреп, ул, елмаеп, болай диде:

– Ә беләсезме нәрсә? Әйдәгез, фотога төшик... Аннары мин бу фотканы сезгә Интернеттан җибәрермен... Булдыра алмасам, миңа оныгымның кызы ярдәм итәр.

Нәкъ әнә шулай – «фотка» диде бабай, әйтерсең, ул Рома белән Зөләйханың яшьтәше.

Шул ук көнне кич белән балаларга әлеге фотосурәт килеп тә иреште.

Анда кыска гына итеп: «Дусларым Зөләйха белән Ромага Ринаттан» дип тә язылган иде.

– Так что 9 Мая для меня и всех нас – самый великий праздник! Тем более сейчас, ведь нынешний 2025 год – юбилейный, **год 80-летия Великой Победы**! Спасибо вам, ребятки, за память. Верность памяти – большое дело. Как я рад, что оно в надёжных руках!

Он помолчал и, заметив, что ребята от похвалы засмущались, с улыбкой добавил:

– А знаете что? Давайте сфотографируемся... Я вам потом фотку по Интернету пришлю... Если что, мне правнучка поможет.

Он так и сказал – «фотку», будто был ровесником Ромы и Зулейхи.

В тот же день вечером ребята получили снимок.

Подписан он был очень коротко: «Зулейхе и Роме от друга Рината».



# ГОРДИМСЯ ПОБЕДОЙ!

1945–2025






Беренче Җиңү парады


Первый Парад Победы

Это интересно

Бу кызык

Иң беренче Җиңү Парады 1945 елның 24 июнендә уза. Мәскәүдәге парад вакытында хәрби техника колоннасы башында һәрвакыт легендар Җиңү танкы – Т-34 бара.

Самый первый Парад Победы прошёл 24 июня 1945 года. Во время парада в Москве во главе колонны боевой техники всегда идёт Т-34 – легендарный танк Победы.



«Җиңү көне» җыры
Песня «День Победы»

Это интересно
Бу кызык

Җырчы Лев Лещенко башкаруындагы «Җиңү көне» халыкның иң популяр һәм яраткан җыры санала. Ул Җиңү бәйрәме концертларында җырланмыйча калмый.

Песня «День Победы» в исполнении певца Льва Лещенко считается самой популярной и любимой военной песней в России. Она обязательно исполняется в День Победы на концертах.

# Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында
# Художники Татарстана о Великой Победе



1985

Әхмәт Китаев

## ҖИҢЕП КАЙТУ

Җиңүче солдат әнисе, хатыны һәм балалары янына кайта. Алай гына да түгел, ул чиксез күк йөзе, күптән сөрелмәгән басу, төтенле пароходлы елгасы булган дөньяга кайта. Бу сюжетта әлеге гаилә өчен иң зур бәхет аларның бергә булулары һәм яшәүләре икәне күренә.

Рәссамның әнисе фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелә, ә абыйсы Сталинград бәрелешендә һәлак була. Сугышның бар дәһшәтен кичергән Әхмәт Китаев кояшлы, ирекле, шатлыклы мохитне күрсәтеп бирә алган. Рәссам үз тамашачыларына бу Җиңүнең ни өчен кирәк булганлыгын сурәтләп бирүне иң мөһим бурыч дип күргән.

Ахмед Китаев

## ВОЗВРАЩЕНИЕ С ПОБЕДОЙ

Солдат-победитель вернулся к матери, жене и детям. А ещё он вернулся к целому миру, в котором есть бескрайнее небо, давно не паханное поле, река с дымящим пароходом. В этом сюжете совсем не важно, что ещё есть у этой семьи, кроме самого большого счастья – быть вместе и просто жить.

Солнечная, свободная, радостная атмосфера передана Ахмедом Китаевым – человеком, пережившим все ужасы войны. Его мать была казнена фашистами, а старший брат погиб под Сталинградом. Художник посчитал важным передать своим зрителям самое главное – то, ради чего была нужна эта Победа.

Җиңү көне турында истәлекләр

День Победы в воспоминаниях

# Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре
# Рисунки детей к юбилею Великой Победы



Радмир Төхвәтуллин рәсеме.
Зәй муниципаль районы гомуми үсеш төрендәге «Алтынчәч» балалар бакчасы

Рисунок Радмира Тухватуллина.
Детский сад общеразвивающего вида «Алтынчеч» Заинского муниципального района



Рамина Фәхриева рәсеме.
Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авылының «Ромашка» балалар бакчасы

Рисунок Рамины Фахреевой.
Детский сад «Ромашка» села Базарные Матаки Алькеевского муниципального района

# Эчтәлек


Татарстан Республикасы Рәисе мөрәҗәгате ........ 2

Сүз башы ........ 4

**Беренче бүлек. Серле сурәт** ........ 6

Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында.
К. Васильев. «Славян хатынның хушлашуы» ........ 18

Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре ........ 19

**Икенче бүлек. Нәкъ менә шул ел** ........ 20

Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында.
Ә. Китаев. «Муса Җәлил Моабит төрмәсендә» ........ 28

Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре ........ 29

**Өченче бүлек. «Пешкабыз ферзьгә әйләнә»** ........ 30

Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында.
Л. Фәттахов. «Коля Курицын – полк улы» ........ 44

Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре ........ 45

**Дүртенче бүлек. Җирдә дә, суда да** ........ 46

Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында.
М. Усманов. «Совет артиллериясе уты астында» ........ 54

Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре ........ 55

**Бишенче бүлек. Барысы да фронт өчен** ........ 56

Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында.
Х. Якупов. «Рәссам. Фронт юллары» ........ 66

Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре ........ 67

**Алтынчы бүлек. Бөек вал** ........ 68

Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында.
Ә. Сәфәргалин. «Фронт юлларында. Шәфкать туташы» ........ 78

Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре ........ 79

**Җиденче бүлек. «Совет информбюросыннан...»** ........ 80

Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында.
А. Родионов. «Сапёрлар» ........ 88

Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре ........ 89

**Сигезенче бүлек. Хәтер – ул галәм** ........ 90

Татарстан рәссамнары Бөек Җиңү турында.
Ә. Китаев. «Җиңеп кайту» ........ 108

Бөек Җиңү юбилеена балалар рәсемнәре ........ 109

ТАТАРСТАН – ФРОНТУ

# Оглавление

Обращение Раиса Республики Татарстан .......... 2
Предисловие .......... 5
**Глава первая. Загадочный снимок** .......... 7
Художники Татарстана о Великой Победе.
К. Васильев. «Прощание славянки» .......... 18
Рисунки детей к юбилею Великой Победы .......... 19
**Глава вторая. Тот самый год** .......... 21
Художники Татарстана о Великой Победе.
А. Китаев. «Муса Джалиль в Моабитской тюрьме» .......... 28
Рисунки детей к юбилею Великой Победы .......... 29
**Глава третья. «Наша пешка выходит в ферзи»** .......... 31
Художники Татарстана о Великой Победе.
Л. Фаттахов. «Коля Курицын – сын полка» .......... 44
Рисунки детей к юбилею Великой Победы .......... 45
**Глава четвёртая. На суше и на море** .......... 47
Художники Татарстана о Великой Победе.
М. Усманов. «Под огнём советской артиллерии» .......... 54
Рисунки детей к юбилею Великой Победы .......... 55
**Глава пятая. Всё для фронта** .......... 57
Художники Татарстана о Великой Победе.
Х. Якупов. «Художник. Дороги фронтовые» .......... 66
Рисунки детей к юбилею Великой Победы .......... 67
**Глава шестая. Великий вал** .......... 69
Художники Татарстана о Великой Победе.
А. Сафаргалин. «На фронтовых дорогах. Медсестра» .......... 78
Рисунки детей к юбилею Великой Победы .......... 79
**Глава седьмая. «От Советского информбюро...»** .......... 81
Художники Татарстана о Великой Победе.
А. Родионов. «Сапёры» .......... 88
Рисунки детей к юбилею Великой Победы .......... 89
**Глава восьмая. Память – это космос** .......... 91
Художники Татарстана о Великой Победе.
А. Китаев. «Возвращение с победой» .......... 108
Рисунки детей к юбилею Великой Победы .......... 109

# ТАТАРСТАН – ФРОНТКА
# ТАТАРСТАН – ФРОНТУ

**Художественное-анимационное издание для детей**
**на татарском и русском языках**
**для семейного чтения и внеурочной деятельности**

Автор проекта
**Лейла Фазлеева**

Руководитель проекта
**Азат Ганиев**

Автор текста
**Борис Вайнер**

Главный редактор
**Алсу Низамеева**

Художественный редактор
**Сергей Киатров**

Научный консультант
**Искандер Гилязов**

Консультанты:
**Расима Шамсутдинова,**
**Лейсан Зинатуллина,**
**Татьяна Курамшина,**
**Наиля Ахунова**

Рецензент
**Гульназ Хамитова**

Литературная редакция:
**Ильгизар Закиев, Марат Ганиев,**
**Фарида Ахметзянова,**
**Фаниса Макарова**

IT-директор
**Дамир Бариев**

Технический директор
**Ильдар Низаметдинов**

Дизайн
**Дмитрия Гиацинтова**

Графическая вёрстка
**Елены Шараповой**

Художники-иллюстраторы:
**Арина Смольская, Анна Гаранина,**
**Юлия Артемьева, Полина Михайлова,**
**Максим Рахмачёв, Лилия Садыкова**

Административная группа:
**Анна Кудрявцева, Асия Галеева,**
**Олег Попов, Ирина Бакирова,**
**Юнус Камалиев**

**Татарское детское издательство**
420047, Казань, 3-я Армавирская, 8.
Тел. (843) 222-00-00
**www.tdpress.ru**

Подписано в печать 1.08.2025
Печать офсетная. Тираж 50 500 экз. Заказ №
Формат 210x270 1/16. Печать офсетная.
Отпечатано в типографии
ООО «ЛД-ПРИНТ»
196643, Россия, Санкт-Петербург, Колпинский р-н, пос. Сапёрный,
ш. Петрозаводское, д. 6, стр. 6. Тел. (812) 462-83-83,
e-mail: office@ldprint.ru

# ТАТАРСТАН – ФРОНТКА



# ТАТАРСТАН – ФРОНТУ

Электронная книга и дополнительные материалы на сайте
www.татарстанфронту.рф

www.татарстанфронту.рф

**БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ХРОНОЛОГИЯСЕ**

# ВАКЫТ ТАСМАСЫ

# 1941 –

## 1941

**БАСЫП КЕРУ**
**ВТОРЖЕНИЕ**

**22 июнь**
Германиянең СССРга һөҗүме

**22 июня**
Нападение Германии на СССР

**22 июнь – 23 июль**
Брест крепосте оборонасы

**22 июня – 23 июля**
Оборона Брестской крепости

**7 ноябрь**
Кызыл мәйданда Мәскәү гарнизоны гаскәрләре парады

**7 ноября**
Парад войск Московского гарнизона на Красной площади

**16 декабрь**
Калинин (хәзер Тверь шәһәре) азат ителә

**16 декабря**
Освобождение Калинина (ныне город Тверь)

## 1942

**БОРЫЛЫШ**
**ПЕРЕЛОМ**

**5 август**
Орёл һәм Белгород азат ителә, Мәскәүдә беренче салют

**5 августа**
Освобождение Орла и Белгорода, первый салют в Москве

**Сентябрь – декабрь**
Днепр өчен сугыш

**Сентябрь – декабрь**
Битва за Днепр

## 1944

**ҺӨҖҮМ**
**НАСТУПЛЕНИЕ**

## 1945

**ҖИҢҮ!**
**ПОБЕДА!**

**13 апрель**
Совет гаскәрләре Австрия башкаласы Венаны ала

**13 апреля**
Взятие советскими войсками Вены, столицы Австрии

**16 апрель – 2 май**
Берлин өчен сугыш

**16 апреля – 2 мая**
Битва за Берлин

# ЛЕНТА ВРЕМЕНИ

**ХРОНОЛОГИЯ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ**

## 1945

**10 июль – 10 сентябрь**
Смоленск сугышы

**10 июля – 10 сентября**
Смоленское сражение

**8 сентябрь**
Ленинград блокадасы башлана

**8 сентября**
Начало блокады Ленинграда

**30 сентябрь**
Мәскәү янындагы сугыш башлана

**30 сентября**
Начало битвы за Москву

**17 июль – 23 ноябрь**
Сталинград сугышы

**17 июля – 23 ноября**
Сталинградская битва

## 1943

**АЛГА КИТЕШ**
**ПРОРЫВ**

**5 июль – 23 август**
Курск сугышы

**5 июля – 23 августа**
Курская битва

**27 гыйнвар**
Ленинград блокададан азат ителә

**27 января**
Снятие блокады Ленинграда

**8 апрель – 12 май**
Кырым операциясе

**8 апреля – 12 мая**
Крымская операция

**15 сентябрь**
Совет гаскәрләре Болгария башкаласы Софиягә керә

**15 сентября**
Вступление советских войск в Софию, столицу Болгарии

**30 апрель**
Рейхстагка Җиңү Байрагы күтәрелә

**30 апреля**
Водружение Знамени Победы над рейхстагом

**8 май**
Фашист Германиясенең капитуляциясе

**8 мая**
Капитуляция фашистской Германии

**9 май**
Бөек Ватан сугышы тәмамлана.
**Җиңү көне!**

**9 мая**
Окончание Великой Отечественной войны.
**День Победы!**

Электронная книга и дополнительные материалы на сайте www.татарстанфронту.рф

ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
www.tdpress.ru

ISBN 978-5-6050161-8-2

9 785605 016182 >